КӨЙСЕЗ ЯЗ

Суыклар аркасында кайбер культураларны кабат чәчәргә туры киләчәк

> 2

САБЫР КЕШЕЛӘР

Авыл укытучысын нәрсәләр борчый?

> 7

СҮНМӘС ЙОЛДЫЗ

Утта янган авылны бөтен татар торгыза

> 7

МИЛЛИ АККОРД

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 67 (29034) | Сишәмбе | 16 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Милли киемнәргә, җыр-биюләргә, истәлекләргә, хәтер-хатирәләргә искиткеч бай үзенчәлекле бу бәйрәм күзләрдән яшьләр дә чыгарды, сөендерде дә, көендерде дә. Шулай булуы гаҗәп тә түгел. Сәхнәгә аяк баскан һәр гаилә тарих битләрен актарды бит. Ә аның төпкелендәниләр генә юк!

tatarstan.ru

НӘСЕЛ ҖЕБЕ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның Архив эшләре буенча дәүләт комитеты оештырган «Тарихта без эзлебез» фестиваленең бишенчесе узды. Чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехanов катнашты. Рәис, беренче чиратта, бәйгедә катнашучыларны да, тамашачыларны да Халыкара гаилә көне белән котлады.

– Еллар үткән саен, без ата-бабаларыбыз, нәсел җепләребез турында күбрәк уйланабыз, – диде ул. – Татарда, җиде бабаңны бел, дигән гыйбарә дә бар бит. Моннан биш ел элек оешкан шәҗәрә фестивале, чыннан да, халкыбыз арасында бик зур популярлык казанды. Иң мөһиме, ул гаиләдәге элемтәләрне ныгытырга ярдәм итә. Һәр гаилә – республикабыз, илебез тарихы.

«Тарихта без эзлебез» проекты 2019 елда башланып киткән иде. Вакыт аз гына үткән кебек югыйсә, әмма эшләнгән эшләр санап бетергесез булып чыкты. Аларның һәрберсе нәселдән-нәселгә килгән гореф-гадәтләрне саклауга, җәмәгатьчелекнең игътибарын тарихны өйрәнүгә юнәлткән.

Фестиваль ел саен өч этапта үткәрелә: башта районнарда оештырыла, җиңеп чыкканнар зона ярышларында катнаша, «иң-иң»нәре республика беренчелегендә көч сынаша. Быел андыйлар алты гаилә иде. Беренче этапта 186 гаилә катнашкан. Зона ярышлары Мөслим, Зәй, Әлки, Балтач, Чүпрәле районнарында үткәрелгән. Анда 47 гаилә үз осталыкларын күрсәткән. Фестивальнең программасы да бик саллы: ул ике өлештән тора. Беренчесендә – гаилә әзерләгән милли ашлар күргәзмәсе, икенчесендә – «Таныш булыгыз: минем гаиләм, минем нәселем!» дип аталган бәйге. Менә шушы бәйгедә ярышучылар үзләрен төрле яклап күрсәтергә омтыла да инде.

Архив эшләре буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Гөлнара Габдрахманова бу чараның тагын бер әһәмиятле ягын ассызыклады. «Шәҗәрә фестивале Татарстанда төрле милләт халыкларының дус һәм тату яшәвен раслый. Моның шулай икәнлегенә төшенү өчен, катнашучылар, я булмаса зона ярышларында җиңүчеләр исемлегенә күз салу да җитә», – диде ул бу җәһәттән.

Аксубай районыннан килгән Андреевлар, мәсәлән, чуаш милләтеннән. Аларның Энтри-Андреев нәселе бик еракка – XVII гасырда Казан губернасындагы Чистай өязенең Сөнчәле авылында туып-үскән Иван Федоровка барып тоташа. Бабалары җир кешесе була: игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Ә хәзер бу нәселдә кемнәр генә юк! Беренче Бөтендөнья, Бөек Ватан сугышында катнашкан бабаларын да искә алдылар, педагоглар, төбәкне өйрәнүчеләр дә шактый булып чыкты.

Ютазы районы данын якларга килгән Абдрахмановлар нәселе исә Дагыстан Республикасыннан юл ала. Ерак бабалары Магомед Харьковны азат итүдә катнаша һәм, контузия алып, әсирлеккә төшә. Репрессияләнгәч, аны Ютазы районына җибәрәләр. Дөрес, аның Дагыстанда гаиләсе була, өч баласы да үсеп килә. Әмма туган якларына кайта алудан өметен өзгән ир-ат яңадан тормыш корырга уйлый: Фатыйма исемле татар кызына өйләнә. Тупырдашып, биш бала туа. Мәдәнияткә һәвәс кешеләр булып чыга аларның нәселе. Күбесе, республика буенча үзешчән сәнгать бәйгеләрендә катнашып, җиңү яулый. Арада Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен алучылар да байтак. «Ютазы йолдызлары» бию ансамблен җитәкләүчеләр дә – шушы нәселдән. Шунысы сокландырды: гаилә Дагыстанда яшәүчеләр белән дә элемтәдә тора. Магомед бабаларының беренче хатынының фотосы әлегә кадәр йорт диварында эленеп тора икән.

Казанның Мәскәү районында яшәүче Лозовой-Ярцевлар гаиләсе исә, 9 буынга кадәр барып җитеп, туган тиешле 693 кешене эзләп тапкан. Алар арасында руслар да, татарлар да, белоруслар, үзбәкләр, украиннар да бар. Һөнәрләре дә күп төрле: табиблар, педагоглар, инженерлар, хәрби хезмәткәрләр, спортчылар, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре – кыскасы, санап бетергесез. Бу нәселдә 14 хезмәт ветераны бар. Педагоглык стажы – 927 ел! Балалар, оныклар бу санны тагын да арттырырлар әле дип тә өметләнәләр.

Хантимеровлар Саба районының Тимершык авылыннан килгән. «Авылда безнең Хантимер бабабыз кулы тимәгән бер генә йорт та булмаган», – ди алар. Баксаң, әле хәзер дә нәсел-нәсәпләре белән балта осталары, йорт салучылар икән. Алтмышынчы елларда бабалары үз нигезләреннән ерак түгел чишмә таба, чистарта. Авылдашлары аны хөрмәт белән «Хантимер чишмәсе» дип йөртә.

Зәй районы Имәнлебаш авылыннан килгән Әхмәтҗановлар исә фамилияләренә тугрылык саклый алганнар. Аларның нәселендә гел татарлар, ялгышып та башка милләт кешесе катышмаган. Чабата үргәндә кулланылган шөлчедәге (анысын чормадан тапканнар) тавык тәпие сурәте аларның нәсел тамгасы булып чыккан. Әллә инде шуның шаукымы, бер улыбыз тавык фермасын җитәкли хәзер, дип көлешеп тә алдылар.

Кайбыч районыннан килгән Гарәфетдиновларның нәсел тамыры исә җырчы Галия Кайбицкаяга барып тоташа. Бабалары Афзалның улы Рәфыйк Гарәфетдинов – тарих фәннәре докторы. Олы Кайбыч авылындагы урамга аның исеме бирелгән, истәлек тактасы да куелган.

Рөстәм Миңнеханов, чара ахырында барлык катнашучыларга да, оештыручыларга да рәхмәт әйтеп, чын күңелдән котлады. «Мондый бәйгедә җиңелүчеләр булмый», – диде ул. Әмма, ничек кенә булса да, мәртәбәле жюрига барыбер җиңүчеләрне билгеләргә туры килә. Шулай итеп, юбилей елында фестивальдә беренче урынга – Саба районыннан Хантимеровлар, икенче урынга – Аксубай районыннан Андреевлар, өченче урынга Казаннан Лозовой-Ярцевлар гаиләсе лаек булды. Барлык катнашучыларга да дипломнар һәм бүләкләр тапшырылды.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

- Биш ел эчендә «Тарихта без эзлебез» фестиваленең өч этабында **700**дән артык гаилә, **10000**нән артык кеше катнашкан.
- Катнашучыларның иң кечкенәсенә – **4** ай, иң өлкәненә – **97** яшь.
- Бер гаиләдән **80**гә якын кеше катнашкан очраклар булган.
- **40** елдан артык бергә яшәүчеләрнең фестивальдә катнашуы – еш очрый торган күренеш.

Рейтингта өченче

Татарстан төбәкләрнең социаль-икътисадый рейтингында, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышып, өченче урынга чыккан. «РИА Новости»ның узган елгы йомгаклар буенча төзелгән рейтингында төп күрсәткечләр – товар җитештерү күләме, эшләүчеләр саны, ваклап сату әйләнеше, табышка эшләүче предприятиеләр өлеше, эшкә сәләтле халык арасында үлем-китем күрсәткече, эшсезләр саны исәпкә алынган.

Беренче дистәгә шулай ук Ханты-Манси автономияле округы – Югра, Мәскәү өлкәсе, Ямал-Ненец автономияле округы, Свердловск өлкәсе кергән. Шул ук вакытта Магадан өлкәсе, Кабарда-Балкар, Төньяк Осетия – Алания, Ингушетия, Алтай, Тыва республикалары рейтингның соңгы унлыгына эләккән.

Исегезгә төшерәбез: 2021 ел йомгаклары буенча да Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Татарстан беренче өчлеккә кергән иде. Ә 2020 елда без бишенче булганбыз.

Чистарыну дәвам итә

Экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков хәбәр иткәнчә, санитария-экология икеайлыгы башланганнан бирле 5 меңнән артыграк закон бозу очрагы ачыкланган. 4111е буенча чаралар күрелгән, барлыгы 1,2 миллион сумлык штраф салынган. Тиешсез урыннарда 3323 чүп өемнәре табылган. Шуларның 79,5 проценты юкка чыгарылган.

Икеайлык чорында районнардан 320 мең кубометрдан артыграк күләмдә көнкүреш калдыгы чүплекләргә озатылган. Чистарыну эшләренә барлыгы 12 меңнән күбрәк берәмлек махсус техника җәлеп ителгән, 587 меңнән артык агач-куак утыртылган.

Яңа мәктәп булыр

Россия Хөкүмәте төбәкләрдә яңа мәктәпләр төзүгә бюджеттан 4,5 миллиард сумнан артыграк акча юллаячак. Министрлар Кабинеты хәбәренә караганда, аны Татарстан, Төньяк Осетия, Приморье крае, Ингушетия, Якутия, шулай ук Пенза һәм Владимир өлкәләре бүлешәчәк.

Премьер-министр Михаил Мишустин билгеләп үткәнчә, төбәкләргә заманча 9 мәктәп төзү, балалар өчен 8 меңнән артыграк өстәмә урын булдыру мөмкинлеге бирәчәк бу.

«Татар-информ»

Соңгы кыңгырау чыңы

Татарстан мәктәпләрендә «Соңгы кыңгырау» бәйрәмнәре 22 һәм 23 майда узачак. Чыгарылыш кичәләре исә – 23 июньнән соң. Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәр иткәнчә, Педагог һәм остаз елында чыгарылыш кичәләре онлайн эфирдан башланачак. Аңа Россиянең барлык мәктәпләре кушылырга мөмкин.

Моннан тыш Россия Мәгърифәт министрлыгы «Җиңүләр марафоны: рәхмәт, укытучым!» дигән акция уздыра. Аның барышында бер ай дәвамында укучылар һәм ата-аналар мәктәп еллары турында, үзләренең мөгаллимнәре һәм остазлары турында министрлыкның «ВКонтакте» социаль челтәрендәге рәсми төркемендә постлар һәм видеороликлар урнаштыра алачак.

Җәйге җылы

Бу атнада Татарстанда җылы һава күтәрелә. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, көндезге температура +26 градуска кадәр җитәр дип фаразлана. Әмма урыны белән яшенле яңгырлар, көчле җил булырга мөмкин.

Чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 17–18 майда явым-төшем көтелми диярлек. Көндез +20…+26 градус җылы. Төнге сәгатьләрдә һава температурасы +5…+13 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, җомга – 19 майда көндез +21…+26 градус җылы булачак. Явым-төшем ихтималы аз.

Тәкъдим

Субсидия, пеш, кесәгә төш

Торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә субсидия алучылар саны күбәеп китмәгәе. Россия Дәүләт Думасы депутатлары бу эшне мөмкин кадәр җиңеләйтергә тәкъдим иткән. Алар әйтүенчә, ярдәм алу өчен халыктан бер гариза да җитә.

Илдә яшәүчеләрне торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә субсидия алу өчен кат-кат кәгазь җыю эшеннән азат итмәкчеләр. Дәүләт Думасының Төзелеш һәм ТКХ комитеты депутатлары әйтүенчә, мондый «кәгазь боткасы»ннан котылырга вакыт. Алар ил Хөкүмәтенә әзерләгән документтан аңлашылганча, ут һәм су өчен түләгәндә, дәүләттән матди ярдәмне бер документ нигезендә генә билгеләргә тәкъдим иткәннәр. Ягъни субсидия кирәклеге турында гариза язасың да, бетте китте. Ә калган мәгълүматны дәүләт оешмаларында эшләүчеләр үзләре табарга тиеш булачак.

– Торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә субсидия билгеләү халыкның артык вакытын алырга һәм сәламәтлеген какшатырга тиеш түгел, – дип белдергән комитет җитәкчесе Сергей Пахомов.

Бу хакта күптән сөйлиләр югыйсә. Тик, кем әйтмешли, көймә һаман да шул урында тора. Гаризаны өйдән чыкмыйча гына Дәүләт хезмәтләре порталы аша тапшырырга мөмкин булса да, социаль яклау бүлекчәләрендә чират. Яңа үзгәрешләр ил күләмендә бу мәсьәләгә чик куярга тиеш, дип белдергән депутатлар.

Депутатлар торак-коммуналь хезмәтләргә түләү субсидиясен билгеләү чиген хәзерге илкүләм 22 проценттан 15 процентка кадәр төшерергә дә тәкъдим иткән. Исегезгә төшерәбез: Россия Торак кодексы нигезендә, социаль нормалар һәм нормативларны исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 22 процентыннан (ил төбәкләре әлеге күрсәткечне киметә ала, әмма моннан югары күтәрергә ярамый) артып киткән гаиләләр аз керемле булып санала һәм субсидиягә өмет итә ала. Рәсми мәгълүматларга караганда, илнең 58 төбәгендә әлеге күрсәткеч – 22 процент, 24 төбәгендә – 15–21 процент, ә өчесендә исә 15 проценттан да кимрәк. Мәсәлән, Татарстанда ул – 21, ә Мәскәүдә – 10 процент.

Субсидия ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырырга кирәк. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт торакның мәйданына бәйле. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә.

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:

– Товар һәм хезмәтләргә бәяләр көннән-көн арта. Хезмәт хаклары исә ул дәрәҗәдә тиз үсми. Шуңа күрә бүген гаиләләрнең чыгымнары бермә-бер артты. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен субсидия билгеләү чиген 15 процентка кадәр төшерү илдә яшәүчеләрнең матди хәлен азмы-күпме җиңеләйтәчәк. Былтыр Татарстанда уртача хезмәт хакы якынча 17 процентка артса, республиканың кайбер районнарында торак-коммуналь хезмәтләр өчен чыгымнар гына да 20 процентка кадәр кыйммәтләнде.

Сүзгә-сүз

Татьяна МОСКАЛЬКОВА, Россиядә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

Узган ел илдә балага алимент түләмәүгә бәйле шикаятьләр саны 26 процентка арткан. Бу – нигездә керемнәре турында дөрес мәгълүмат җиткермәүчеләргә бәйле. Әлеге мәсьәләдә нәтиҗәлелекне арттыру өчен илдә дәүләт алимент фонды булдырырга тәкъдим итәм. Вакытында түләнмәгән алимент акчасын әнә шуннан алырга мөмкин булачак.

РОССИЯЛЕЛӘРНЕҢ ЧЫГЫМНАРЫ

«Зарплата.ру» хезмәте Россиядә яшәүчеләрнең чыгымнарын исәпләгән. Быел халыкның 75 проценты акчасын кысыбрак тота башлаган.

АКЧАНЫ НӘРСӘГӘ АЗРАК САРЫФ ИТӘСЕЗ?

41% – «бар нәрсәгә дә»

13% – кафе-рестораннар	8% – матурлык салоны
12% – ял, сәфәрләр	5% – хәмер
9% – азык-төлек	2% – мебель
9% – кием-салым	1% – техника



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТӨРКИЯ: КИЕРЕНКЕЛЕК НОКТАСЫНДА КАЙНАГАНДА

Үткән якшәмбедә Төркия дөнья сәясәтенең үзәгенә әверелде. Көнбатышта да, Көнчыгышта да, Россиядә дә күзләр игътибар белән төрек сайлавына текәлде. 14 май сайлавы глобаль үзгәрешләргә старт бирергә мөмкин иде.

Европа белән Азия чигендә урнашкан дәүләт, бердән, геосәяси яктан зур әһәмияткә ия, икенчедән, хәрби һәм технологик куәтен кискен арттырып, үзен дөньякүләм держава буларак игълан итә. Шул коалициянең бер состав өлеше булуга карамастан, башында АКШ торган көнбатыш дәүләтләр берләшмәсенә күп кенә очракларда кискен каршы чыга. Башбирмәс төрек сәясәтен Әрдоган – харизмасы ташып торган лидер билгели иде. 14 май я Әрдоганның лидерлыгын ныгытып, аңа тагын бер срокка карт-бланш бирергә, я күп еллар буе алыштыргысыз идарә иткән лидерны түнтәреп, төрек сәясәтендә кискен борылыш башларга тиеш иде.

Сайлау Әрдоган һәм идарәче партия өчен авыр сынауга әверелде, чөнки яңа гына ил кешелек тарихында сирәк очрый торган масштаблы җир тетрәү фаҗигасе кичерде, эчке базарда инфляция котырына, милли валюта девальвацияләнә. Шуларга өстәп, ислам яклы һәм исламга каршы көчләрнең каршылыгы кискен конфликт дәрәҗәсенә җитеп көчәя. Соңгысы илне көчләр чагыштырмасы якынча тигез булган ике лагерьга – үзләрен кемалчылар дип атаган Ататөрек тарафдарларына һәм мөселман җәмгыятенә бүлде. Эш тагын шуның белән катлаулана: мөселманнарның да байтагы илдәге вазгыятьтә Әрдоганны гаепли һәм аңа каршы позиция сайлый. Бюллетеньда дүрт кандидат булса да, көрәшнең Әрдоган һәм аның оппоненты Кемаль Кылычдароглу арасында барачагы алдан ук мәгълүм иде. Дөньявилыкны һәм ЛГБТ җәмәгатьчелеген яклаучы Кылычдароглуны Әнкара һәм Истанбул мэрлары яклый, ул Көнбатышта да зур теләктәшлек таба. Россиядән аермалы буларак, Төркиядә сайлау нәтиҗәләрен алдан чамалап булмый, шуңа күрә ул һәрвакыт интригалы була, соңгы сайлау исә интригалар шкаласында тиңе булмаган югарылыкка сикерде. Кем җиңсә дә, ил зур турбулентлык чорына кереп китәргә мөмкин, Сүриядә яисә 2013–2014 елларда Украинада булганга охшаш хәлләр башлану ихтималы да юк түгел.

Якшәмбе кичендә тавышларны сайлау процессында ук вазгыять нык куерды. Төрекләрнең рәсми «Анадолу» агентлыгы Әрдоганның шактый ук аерма белән лидерлык итүен игълан итеп барды, оппозицияне яклаучы ANKA исә өстенлек Кылычдароглу ягында дип ут салды. Истанбул мэры Имамоглу: «Алар, чыгып, үз җиңүләрен игълан итсә, ышанмагыз», – дип коткы таратты. Саналган бюллетеньнар саны арткан саен, Әрдоганның өстенлеге кимеде, иртәнге сәгать дүртләрдә инде аңа тавыш бирүчеләр саны илле проценттан түбәнәйде. Гамәлдәге Президент өстенлекне саклады саклавын, әмма беренче турда ук җиңү бәхетеннән колак какты. Бу юллар язылганда, тавышлар тулысынча ук саналып бетмәгән, әмма икенче турның котылгысызлыгы шәйләнә инде. Әрдоган партиясе парламентка сайлауда җиңеп бара. Идарәче коалициянең 600 урынның 322сен яулавы мәгълүм инде. Икенче тур Әрдоган өчен җиңел булмаячак, моны алдан әйтәбез.

Россиядә

ПРИСТАВЛАР ТОТСА ЯКАҢ...

Россиянең социаль-икътисадый тормышында уңай яклар да, тискәре яклар да шәйләнә. Статистика, товарларга һәм хезмәтләргә ихтыяҗ арта, дип сөендерә. Бу –җитештерү артуга китерергә тиешле хәбәр. Илнең бюджет дефициты еллык фаразланган күләмне апрель аенда ук узып китте ләкин. Кытлык 3,42 триллион сумга җитте.

Бюджет төзүчеләр ел ахырына гына 2,93 триллион сумлык дефицит булыр дип планлаштырган иде. Еллык норманы ярты триллион сумга узып та киткәннәр инде. Бу гаҗәп түгел: нефть-газ керемнәре кискен кими, чыгымнар арта. Җитмәгән акча күләме Мәскәү өлкәсенең өч еллык бюджеты, Новосибирск өлкәсенең 11 еллык бюджеты кадәр. Сан никадәр генә зур булмасын, бюджетны Милли байлык фондындагы саклык акча коткара әлегә.

Бурычка акча җыйган россиялеләрнең исә резервлары юк, шуңа әҗәтен түли алмаучылар саны арта. Суд приставлары федераль хезмәте директоры Дмитрий Аристов моны «супер чиктән тыш актуаль проблема» дип бәяли. Кредитоманнар армиясе 2 триллион сум тирәсе бурычын каплый алмый икән. Эш яшендәге кешеләр санына бүлгәч, бурычлар күләме һәр кешегә уртача 360 мең сум туры килә. Кемнәрдер миллионлаган сум әҗәтләр өстендә утыра һәм аларны түли алмый дигән сүз бу. Аристов әйтүенчә, суд приставлары кулында бүген банкларга, микрофинанс оешмаларына һәм коллекторларга түләнмәгән бурычлар буенча 12 миллион документ җыелган. Әмма түләнмәгән әҗәтләрнең күпчелеге әлегә приставларга кадәр барып җитмәгән.

Үзәк банк күптән чаң суга инде. Акчасын хезмәт хакы алганга кадәр җиткерә алмыйча, микрофинанс оешмаларына мөрәҗәгать итүче аз керемле россиялеләрнең проблемалары артуын искәртә. Кулында микрозаем килешүе булучылар саны үткән ел ук 20 миллион кешегә җиткән. Бу алдагы елга караганда 3 миллионга күбрәк. Росстат, билгеле, илдә фәкыйрьләр саны кими, дип югары җитәкчелекне шатландыра ала. Микрозаем алучыларның күбесе майларына чыдый алмаганнан рибачылар каршына килеп басмыйдыр дип уйларга туры килә. Күпчелекне зур процентлы микрозаемнар алырга фәкыйрьлек мәҗбүр итә торгандыр.

Гади халык кына түгел, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр дә бурыч түли алмаудан интегә. Боларның кичектерелгән әҗәте, Үзәк банк мәгълүматларына караганда, 2,8 триллион сумга җитә икән. Банкротлыкка китерүче төп сәбәпләр арасында «керемнәр кимү» дигәне беренче урында тора. Димәк, федераль бюджетның гына түгел, кара халыкның һәм кече бизнесның да керемнәре кими. Чыгымнар исә арта. Бу тозактан чыга алмаучыларның якасыннан приставлар тота инде, нишлисең.

ЭШЧЕНЕҢ КАДЕРЛЕ ЧАГЫ

Казан вертолёт заводында эшләүче 156 кеше, бер көн эчендә барлык белгечләрне узып, сәламәтлеген тикшертте. Кичә завод ишегалдына килеп урнашкан ике күчмә хастаханә машинасы биредә атна дәвамында эшләячәк. Шул рәвешле биредә хезмәт куючы һәркем заводтан читкә чыкмыйча гына табибта тикшеренү узачак.

Әлеге проект «Бердәм Россия» партиясе башлап җибәргән «Эш урынындагы сәламәтлек» акциясе кысасында тормышка ашырыла. Республикадагы 350 оешмада эшләүче барлык хезмәткәрләрнең сәламәтлеген тикшерергә җыеналар.

Татарстанда «Сәламәт киләчәк» федераль проектының иҗтимагый советы рәисе, Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов сүзләренә караганда, бу акцияне нәкъ менә башкаланың вертолет заводында башлап җибәрүләре юкка гына түгел. Бүген биредә эшчеләрнең сәламәтлеген саклауга зур игътибар бирелә. Әле узган ел гына бу максаттан барлыгы 10 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Заводның сәламәтлек саклау пунктында эшчеләр, анализлар тапшырып, невролог, кардиолог, эндокринолог кебек тар профильле белгечләргә дә языла ала. Җыючы-ябыштыручы кебек авыр хезмәттәгеләр өчен махсус физиотерапия кабинеты да эшли. Быел 1 июньнән заводта диспансеризация уздырылачак. Кешегә эшләү генә түгел, ял итү, спорт белән шөгыльләнү өчен дә шартлар тудырылган.

– Шушы эшне бөтен республика күләмендә популярлаштырасыбыз килә. Моннан тыш авыл җирендә, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләрнең сәламәтлегенә дә аерым игътибар итәсе иде. Иҗтимагый советның чираттагы утырышын берәр авыл җирлегендә уздырып, салада яшәп эшләүчеләрнең сәламәтлеген кайгырту мәсьәләсен дә күтәрергә җыенабыз, – диде Айрат Фәррахов иҗтимагый совет утырышында.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин дә моны партия проекты кысасында куелган иң төп максатларның берсе дип атады.

– Әлеге проект ярдәмендә республика оешмаларында эшләүче барлык хезмәткәрләрнең сәламәтлеген ныгытырбыз дип өметләнәбез. Безне алда бик кызык, кирәкле, җитди эш көтә. Кеше сәламәтлеген саклау мәсьәләсе беренче тапкыр гына күтәрелми. Заводлар, фабрикаларда, бигрәк тә нефть, газ, химия тармакларында эшләүчеләрдә һөнәренә бәйле җитди авырулар да пәйда булырга мөмкин. Ул яктан авыл җирендә яшәүче халкыбызның хәле ничек? Язгы чәчү эшләре, җиргә ашлама кертү, химик чаралар белән эшкәртү шулай ук эзсез узмый бит. Моңа да зур игътибар бирергә кирәк, – дип искәртте парламент башлыгы.

Халыкара хезмәт оешмасы (МОТ) мәгълүматларына караганда, җитештерүдә килеп чыккан фаҗигале очраклар, һөнәри авырулар аркасында дөньяда көн саен 6,3 мең чамасы кешенең гомере өзелә. Бер ел эчендә исә андый фаҗигале очраклар саны 2 миллионнан арта. 2019 елда тормышыбызга үтеп кергән коронавирус вазгыятьне тагын да катлауландырган. «Шуңа күрә эшләү яшендәге халыкның сәламәтлеген саклау стратегик дәрәҗәдәге мөһим мәсьәлә булып тора», – ди Айрат Фәррахов. Республиканың сәнәгать тармагы эшчәнлегенә багышланган утырышларның берсендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та сәламәтлек саклау, җитештерү тармагы хезмәткәрләре һәм эш бирүчеләр алдына шундый бурыч куйган иде.

Яшерен-батырын түгел, бүген бу өлкәдә шактый кытыршылыклар бар. Иҗтимагый совет утырышында катнашучылар аларның һәркайсына аерым тукталып, мәсьәләне чишү юлларын табарга тырышты. Завод, фабрика кебек оешмаларда эшләүчеләрнең саулыгын ныгыту, гомерен озайту өчен, иң беренче чиратта хастаханәләр белән хезмәттәшлекне көйләргә кирәк дип саный белгечләр. Оешмадагы сәламәтлек саклау пункты белән хезмәткәр беркетелгән дәвалау оешмасы арасында элемтә булсын, кыскасы. Берсендә анализ тапшырган, тикшеренү узган икән, бу хакта автомат рәвештә икенчесенә дә хәбәр килсен.

– Шул очракта бүген башлап җибәргән акция дә, эшчеләр өчен хезмәт урынында оештырылган диспансеризация дә күпкә нәтиҗәлерәк булыр иде. Төгәл диагноз куелган кеше генә түгел, анализлары начар булган кеше дә, эшне ярты юлда калдырмыйча, кирәкле табибына барып җитәрлек булсын, – ди белгечләр.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин фикеренчә, шәхси медицина оешмалары белән дә элемтәне җайларга кирәк. Юкса аларның күбесе бүген аерым хуҗалык кебегрәк яши. «Билгеле, бүген эшчеләрнең күбесе шәхси медицина оешмаларында да тикшерелә. Шуңа күрә бу эшченең сәламәтлеге турында аларда булган мәгълүматны автомат рәвештә аның эш урынындагы дәвалау оешмасына тапшыру юлларын да булдырырга кирәк», – диде министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«Татар-информ»

Фәрит Мөхәммәтшин мәктәп волейбол лигасы җиңүчеләрен бүләкләде.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, республиканың волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин мәктәп волейбол лигасы җиңүчеләрен бүләкләде. Турнирның финал уеннары «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә узды.

Быелгы ярышта Татарстандагы 740 мәктәптән 5 мең команда, 27 меңнән артык укучы чыгыш ясады. «Мондый проектлар ярдәмендә республикада волейбол бер башка үсте. Бу – Татарстанда яшәүчеләрнең иң яраткан спорт төрләреннән берсе», – диде Фәрит Мөхәммәтшин тантанада. Татарстаннан үрнәк алып, мәктәп лигалары илнең башка төбәкләрендә дә оештырылды. Ил күләмендә узган тәүге турнирда 10 төбәктән 2128 мәктәп, 7 мең команда һәм 62 мең укучы чыгыш ясады.

Әле берничә көн элек кенә «Зенит-Казан» командасы 11нче мәртәбә ил чемпионы булып танылды. «Мондый җиңүләр – уенчылар, тренерлар, белгечләр һәм менеджерларның көндәлек зур хезмәте. Ә бүген сез – җиңүчеләр! Бердәмлек, тырышлык, команда рухы һәм волейболны ярату нәтиҗәсендә хыяллар тормышка ашканын, җиңүгә омтылыш ныгыганын дәлилләдегез. Димәк, безнең арада җиңелүчеләр юк», – диде Дәүләт Советы Рәисе яшьләргә.

Татарстанның мәктәп волейбол лигасында быел кызлар арасында беренче урынны Казанның Идел буе районындагы 6 нчы гимназия укучылары яулады. Икенче урында – Яшел Үзән районындагы Норлат мәктәбе кызлары. Чаллыдагы 60 нчы мәктәп укучылары өченче булды. Егетләр турнирын Баулыдагы 2 нче мәктәп укучылары отты. Базарлы Матак бистәсендәге (Әлки районы) Нәби Дәүли исемендәге гимназия егетләре – икенче, Шәмәрдән бистәсендәге (Саба районы) «Үсеш» лицеенда белем алучы егетләр өченче булды.

РОССИЯ – ИСЛАМСКИЙ МИР KAZANFORUM

АБРУЙЛЫ ҖЫЕН

Дөньяның 80 иленнән 15 меңгә якын кунак, 200дән артык эшлекле һәм мәдәни чара. Казанда бу атнада «Россия – ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумы узачак.

Путиннан сәлам

Халыкара икътисадый форум катнашучыларын Россия Президенты Владимир Путин сәламләде. Әлеге эчтәлектәге телеграмма Кремль сайтында басылды.

«Татарстан башкаласы чираттагы мәртәбә киң колачлы, эшлекле чаралар үткәрү өчен кирәкле һәм абруйлы мәйдан статусын раслап, күп кенә илләрдән килгән кунакларны җылы каршы ала.

Россияне мөселман илләре белән ике яклы элемтәләр буенча да, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән эшләү кысасында да тыгыз һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр бәйли. Алар үзара хезмәттәшлек, бер-берeңнең суверенитетын, үсеш үзенчәлекләрен хөрмәт итүгә корылган. Безне халыкара хокукларга нигезләнгән гадел һәм киңкырлы дөнья төзелешен булдыруга омтылыш берләштерә.

Бүген ислам илләре актив рәвештә үсә, финанс һәм сәүдә, инновацияләр һәм фәнни-гамәли тикшеренүләр өлкәләрендә зур уңышларга ирешә. Россия алар белән эшлекле һәм гуманитар хезмәттәшлек өчен ачык. Безне гамәлдәге мөнәсәбәтләрне ныгыту, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать кооперацияләрен үстерү, яңа транспорт-логистика челтәрләрен булдыруда яңа хезмәттәшләр табу кызыксындыра. Россия мөселманнарының халыкара элемтәләрне ныгытуда мөһим урын алып торуын да билгеләп үтәсем килә. Әлеге форум моны тагын бер кат раслый.

«Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме һәм «KazanForum» Халыкара икътисадый форумы эшчәнлеге киләчәктә дә Россия һәм мөселман илләре бизнес-берләшмәләре арасында үзара хезмәттәшлекне ныгытуга ярдәм итәр, төбәкара һәм дәүләтара дәрәҗәдә уртак проектлар өчен яңа мөмкинлекләр ачар дип ышанам», – диелә сәлам хатында.

Килешүләр әзер

«KazanForum»да имзалау өчен 100дән артык килешү әзерләгәннәр. Бу хакта «Интерфакс»ка биргән әңгәмәсендә Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина әйткән.

– Быел имзаланачак килешүләрнең иң зурлары Төньяк-Көньяк халыкара транспорт коридорына бәйле. Мәсәлән, Татарстанда җитештерелгән техниканы Үзбәкстанга озату, Азәрбайҗанда «Sollers» компаниясе сәнәгатен җәелдерүгә бәйле килешүләр бар, – дигән ул. – Инвестиция проектлары – зур һәм катлаулы эш. Алар бер көндә генә тормышка ашмый. Дөрес, аерым мисаллар да бар. Мәсәлән, 2022 елда форум мәйданында Казан һәм «Сбербанк» арасында төзелгән килешү нигезендә, узган елның азагында ук башкалада партнерлык финанслары буенча эшләүче банк бүлекчәсе ачылды. Сүз уңаеннан, бүген республикада 16 оешма ислам финанслары буенча хезмәт күрсәтә.

Хәләл ярминкә

Форум көннәрендә Казан «Агропарк»ында «Russia Halal Market 2023» ярминкәсе эшләячәк. Керү бушлай. Хәләл ярминкә үткәрү өчен бинаны тулысынча юып чыгарганнар. 18–21 май көннәрендә биредә Татарстан һәм Россия төбәкләреннән генә түгел, ә чит илләрдән дә 400дән артык хәләл сәүдә ноктасы эшләячәк дип көтелә.

БЕЛГЕЧЛӘР:

«САЛКЫННАР КӨТЕЛГӘН УҢЫШНЫ БИРМӘС»

Татарстанда чәчү эшләре акрынлап ахырына якынлаша. Чәчүне тәмамлаган районнар да бар, тик суыклар аркасында кайбер культураларны кабаттан чәчәргә туры киләчәк. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының соңгы мәгълүматлары буенча, бүген язгы культуралар 1 млн 776,7 мең гектар мәйданда чәчелгән.

«Татар-информ»/Салават Камалетдинов

Бу – планның 96 проценты дигән сүз. Алексеевск, Әлки, Әтнә, Зәй, Яшел Үзән, Нурлат, Сарман һәм Ютазы районнары чәчү кампаниясен беренчеләрдән булып тәмамлаган.

– Без чәчүгә 5 апрельдә чыккан идек. 1 майга төп культураларны чәчеп тәмамлаган идек инде. Быел ел үзенчәлекле булды. Эшләр җиңел, уңай барды, – диде Зәй районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Фәргат Камалиев.

Кызганыч, узган атнадагы суыклар игеннәр өчен эзсез узмады. Авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров Хөкүмәт йортындагы чыгышында әйткәнчә, республикадагы 30 мең гектарга якын чәчүлек зыян күргән. Аларның иң зур өлеше Баулы, Лениногорск, Минзәлә районнарына туры килә. Әлеге кишәрлекләрдә яңадан чәчү планлаштырыла. Шуңа бәйле рәвештә министр гадәттән тыш хәлләр вакытында чәчүлекләрне иминиятләштерү кирәклеген тагын бер кат искәртте. Бүген иминиятләштерелгән чәчүлекләр мәйданы 509 мең гектар тәшкил итә.

Әйтик, Минзәлә районында 7 мең гектардан артык мәйданда культуралар өшегән.

– Бездә һава температурасы 6–8 майда – 10…–12 градуска кадәр суытты. Нәтиҗәдә 7 мең гектардан артык мәйдандагы культуралар өшеде, – диде районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Илфар Халиков. – Көзге бодай, арпа, борчак, рапс, шикәр чөгендере, көнбагыш культураларына зыян килде.

Җитәкче әйтүенчә, алар урынына чәчү вакытлары соңармаган культуралар чәчәргә туры киләчәк. Бераз гына зыян килгән культураларны исә терлек азыгы буларак файдаланырга уйлыйлар.

– Мин 20 елдан артык авыл хуҗалыгында эшлим, тик мондый хәл белән беренче тапкыр очрашам. Салкыннар була иде, ләкин мондый күләмдә зыян күргән юк иде. Моңа, бердән, апрельдә явым-төшемнең аз булуы һәм суыкларның озакка сузылуы йогынты ясады. 4 айга нибары 63 мм явым-төшем булды. Узган ел 180 мм иде. 12 градус суыкта үсемлекләр йокыга тала бит инде. Бу салкыннар иген культураларына гына түгел, агачларга да начар. Май азакларында люцернаның беренче катын чабып алырга планлаштыра идек. Бу суыклар аларны да үстермәячәк. Ләкин аны чапмыйча, уңышның икенче катын да алып булмаячак. Бигрәк тә су буйларындагы кырларга авырга туры килде. Иртә чәчелде, яңгыры булмады. Әле дә яңгыр юк. Кәеф төште, әлбәттә. Чәчү эшләре тәмамланып килә, кукуруз гына чәчәсе калган иде. Бу хәлләр хуҗалыкларга авырга туры килде. Алар бик зур суммада акча югалтты. 2 мең гектар чәчүлек мәйданына зыян килгән хуҗалык бар. Шуның 1100 гектары – рапс. Нәтиҗәдә 18 млн сумнан артык зыян салынды, – диде ул.

Зәй районында да суыклар булды.

– Төнлә өч көн рәттән ун градуска кадәр суык булды. Якынча 1 мең гектар тирәсе мәйданда шикәр чөгендерен кабат чәчәргә туры киләчәк. Аны чәчәргә вакыт бар әле. Анысы өчен борчылмыйбыз. Дөрес, орлык кайтканны бераз көтәргә туры килер, ахры. Бездә арпаны кырау суккан иде инде. Алар әйбәт кенә китте. Бераз гына яңгыр явып узу да нәтиҗәсен бирде, – диде Фәргат Камалиев.

Аның фикеренчә, әлеге суыклар уңдырышлылыкка да йогынты ясаячак.

– Озак еллар баш агроном булып эшләгән белгечебез әйтүенчә, 60 ел эчендә мондый яз булмаган, – ди Фәргат Камалиев. – Иртә килгән яз яңгырсыз һәм суык булды. Бу салкыннар көтелгән уңышны бирмәс, дип уйлыйм. Арпа кабаттан яшелләнеп китсә дә, уңдырышлылыгының күпмесендер югалтты. Чөгендер дә узган елдагы кебек яхшы уңыш бирмәс, дип уйлыйм.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫНЫҢ 2022 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ГРАЖДАНЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ ИНСТИТУТЛАРЫ ТОРЫШЫ ҺӘМ ҮСЕШЕ ТУРЫНДА ДОКЛАДЫ

Казан **2023**

Кереш

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында»гы 2017 елның 27 апрелендә дөнья күргән 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 маддәсе нигезендә, ел тәмамлангач, Иҗтимагый палата Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында доклад әзерли, анда җәмгыятьнең тормышына йогынты ясаган граждан инициативалары, коммерциячел булмаган секторны үстерү векторларын билгеләгән мөһим вакыйгалар һәм юнәлешләр карала.

Узган 2022 ел халыкара мөнәсәбәтләр архитектурасында моңарчы күрелмәгән үзгәрешләр елы буларак бик күп билгеләмәләр алды. Икътисадый, мәдәни, спорт һәм башка үзара бәйләнешләр илебезгә максатчан басым ясау, санкцияләр, предприятиеләргә һәм конкрет гражданнарга карата чикләүләр кертү нәтиҗәсендә җимерелде. Бер үк вакытта мәгълүмат сугышы башланды. Бу фонда илдә һәм республикада ил икътисадының тотрыклылыгын саклау, актив социаль сәясәт алып бару буенча моңарчы булмаган чаралар күрелде.

Узган ел бердәмлек һәм моңарчы күрелмәгән гражданлык активлыгы елы булды: шәхси инициативалар, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү, иҗтимагый оешмаларның, гуманитар ярдәм җыю хәрәкәтләренең акцияләре конкрет гаиләләрнең, Луганск Халык Республикасындагы балаларның, Татарстанда мобилизацияләнгәннәрнең һәм аларның гаиләләренең мәсьәләләрен хәл итәргә булышты.

Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы өчен милләтара һәм конфессияара татулык кыйммәтләре беренче чиратта калды. Узган 2022 ел Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү белән истәлекле булды. Бу мөһим дата Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин боерыгы нигезендә билгеләп үтелде һәм Россия халыкларының мәдәни мирасы елында иң мөһим гомумфедераль темага әверелде.

Төрле конфессияләр һәм илебездә яшәүче халыклар, фән һәм коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре арасында диалог мәйданчыклары шактый киңәйде, аларда Россия исламы тарихы, диннәрнең күп гасырлык хезмәттәшлеге традицияләре, конфессияара һәм милләтара татулыкны саклауның заманча практикалары турында фикер алыштылар. Күп гражданнар катнашында уздырылган гомумфедераль һәм төбәк юбилей чаралары җәмәгать иминлеген саклауның ныклы нигезе булып тора.

Гражданлык җәмгыятенең үз традицион кыйммәтләрен сакларга һәм үстерергә, тышкы социаль чакыруларга җавап бирергә әзер торуы гражданлык җәмәгатьчелеге белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте арасындагы тотрыклы мөнәсәбәтләрне һәм ачык коммуникацияләрне тагын бер кат раслады.

1. Гражданнар бердәмлеге – яңа практикалар

2022 ел безнең республикада, гомумән илдәге кебек үк, җәмгыять һәм дәүләт көчләренең берләшүе, бердәмлек һәм теләктәшлек белән ассызыкланды. Санкцияләр шартларында оператив рәвештә яңа логистика, аналоглар җитештерү җайга салынды, параллель импорт программалары гамәлгә ашырыла, экспорт каналлары Европадан Азиягә юнәлдерелде, эре җитештерүчеләргә, кече бизнеска ярдәм күрсәтелде. Республика хакимияте органнарының тәвәккәл һәм оператив гамәлләрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның роле аеруча мөһим, ул якын һәм ерак чит илләр белән яңа элемтәләр төзүдә, яңа партнерлар эзләүдә зур көч куя.

Татарстан Республикасы җитәкчелегенең омтылышын иҗтимагый хәрәкәт тә хуплады. Социаль җаваплылык һәм актив гражданлык позициясе иҗтимагый акцияләрдә һәм чараларда күренә.

Эвакуацияләнгәннәрне кабул итү буенча эшне координацияләүне беренче вице-премьер Р.К. Нигъмәтуллин җитәкчелегендәге республика штабы алып барды. Штаб куйган бурычлар кысаларында 2022 елның 22 февралендә ТР Иҗтимагый палатасы рәисе З.Р. Вәлиеваның коммерциячел булмаган оешма вәкилләре, Луганск һәм Донецк Республикаларыннан эвакуацияләнгәннәрне (алар арасында күпчелеге хатын-кызлар һәм балалар иде) урнаштыру планлаштырылган муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары белән очрашуы узды. Иҗтимагый оешмалар, коммерциячел булмаган сектор вәкилләре шулай ук республикага килүче хатын-кызларга һәм балаларга ярдәм күрсәтүдә, гуманитар ярдәм җыюда катнашырга әзер булуларын белдерделәр. Бер үк вакытта НКО вәкилләре бертавыштан «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» фондындагы коллегаларына акча җыю буенча махсус счет ачуны йөкләргә карар кылды. Алар кирәкле җылы әйберләр, балалар кирәк-яраклары һәм азык-төлек, гигиена әйберләре җыюны, профильле НКО хезмәтләре күрсәтүне оештырдылар.

Бер үк вакытта зур күләмдә граждан инициативалары да күбәйде. Чаллыдан Рөстәм Гатин Лисичанск халкы өчен кайнар ризык оештырырга тәкъдим итте. Күп газап күргән шәһәр тормышын бүген көн саен 5000 кешене тукландыручы кыр кухнясы булган бу командадан башка күз алдына китерү кыен. Яшел Үзән районыннан фермер Алексей Чигаров мобилизацияләнгәннәр өчен мичләр ясый башлады. Казаннан профессиональ хәрби Евгений Жемков, сугыш хәрәкәтләре зонасыннан кайткач, хәрби операциядә катнашучыларга кирәкле әйберләр җыюны оештыра (җылы пирчәткәләр, оекбашлар, резин итекләр, кием һәм шешәләргә салынган су). Кирәкле әйберләрнең беренче исемлеген ул үз акчасына җыя. Хәзер аның башлангычында бу эштә күп кенә казанлылар катнаша. Мамадыш халкы 300 пардан артык җылы оекбаш җыя.

Берничә килограмм азык-төлекне солдатларга апалы-сеңелле Мария Астраханова белән Елизавета Сорокина тапшырды. Әйбер җыюда «Ак калфак»ның Мамадыш бүлекчәсе әгъзалары актив катнашты. Марина Куцакова – Биектау районы волонтерлар хәрәкәте лидеры, эшмәкәр, заказ буенча җиһаз җитештерүче, хәрби операция башлангач, көне ике өлешкә бүленә: бизнес һәм граждан инициативасы. Офисы гуманитар ярдәм кабул итү пунктына әверелә, анда Биектау районы халкы хәрбиләр өчен кирәкле әйберләр китерә, гуманитар ярдәм җибәрүне координацияләүдән тыш, ул Лисичанскиның тыныч халкына һәм Луганск Сабыйлар йортында яшәүче балаларга ярдәм күрсәтә. Марина шулай ук остаханә оештыра, анда гражданнар килә һәм мобилизацияләнгәннәр өчен кием-салым, балаклавалар һәм яшеренү халатлары тегәләр. Азнакай районы Сәпәй авылы халкы оекбаш, бияләй, шарфяка бәйләү өчен җеп әзерләде. 4 октябрьгә 766 пар оекбаш, 200 пар бияләй бәйләде.

Казан шәһәреннән «Фәрештәнең алтын куллары» волонтерлар төркеме, Бөгелмә һәм Баулы шәһәрләреннән волонтерлар сәнәгать машиналарында тегә торган носилка эшләнмәләре әзерләде. Материалларны Мәскәүдән җибәрәләр. Носилкалардан тыш, монда дару тартмалары, сумкалар, утыру өчен келәмнәр ясыйлар. Казан тукыма кибетләре япмалар һәм мендәрләр өчен тукымалар алып килә. Шунда ук эвакуация кирәк-ярагы тегәләр. Волонтерлар төркемендә барлыгы 20 кеше, нигездә хатын-кызлар. Кукмарада Людмила Павлова ВИП сәүдә үзәгенең икенче катындагы бинаны арендага ала һәм хезмәттәшләре белән бергә маскировка костюмнары тегә. Бина хуҗасы артык тукыманы саклау өчен бүлмә бирә. Ирина Иванова компьютер аша лекало чыгара, фурнитура китерә. Материал белән районның битараф булмаган халкы һәм «Сугышчан туганлык» иҗтимагый оешмасы тәэмин итә. КФУның 6 студенты, шул исәптән 2 нче курс студенты Альбина Әмирова дизайн һәм пространство сәнгате институты директоры Карина Нәбиуллина җитәкчелегендә хәрбиләрнең экипировкасы предметларын үзгәртәләр, укудан буш вакытта үзләре тегәләр дә. Волонтер Альбина Сәйфетдинова – урман хуҗалыгы хезмәткәре, декрет ялында булганда, коллегалары белән бергә Әлмәт шәһәр паркы кафесында маскировка костюмнары ясаганнар һәм маскировка челтәрләре үреп йөргәннәр. Маскировка челтәрләрен үрү буенча бөтенроссия хәрәкәтенә Чаллы, Казан, Алабуга, Менделеевск, Тукай, Баулы һәм Минзәлә районнарының 500дән артык кешесе кушылды. Материалларны оператив җыю өчен «Баулы Масксеткалары» (700гә якын язылучы) һәм «Казан Масксеткалары» (1000нән артык язылучы) дип исемләнгән ике телеграм-канал төзелде.

«Татарстан хатын-кызлары» төбәк бүлеге 2022 елның 23 мартыннан 11 апреленә кадәр Россия хатын-кызлар берлеге игълан иткән «Сугышчыга бүләк» бөтенроссия акциясен хуплады. Җыенда «Татарстан хатын-кызлары» бүлегенең 28 муниципаль бүлекчәсе, «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе, «Бәхетле» компаниясе катнашты. Шәһәрләрдә һәм районнарда хатын-кызлар инициативасына дини, ветеран һәм башка иҗтимагый оешмалар кушылды. Кешеләр берәм-берәм һәм бөтен гаиләләр белән бүләкләр алып килде. Һәрбер посылкага, күчтәнәчләрдән һәм беренче кирәкле әйберләрдән тыш, үзенчәлекле талисманнар – яхшы теләкләр һәм теләктәшлек сүзләре белән открыткалар, балалар рәсемнәре салынды. Солдат паегында булмаган нәрсәгә дә – тәмле чәкчәккә һәм Татарстан балына урын табылды. Махсус операциядә катнашучылар өчен 29,5 тонна авырлыктагы 3175 тартма җыелды һәм озатылды.

Онкологиядән дәваланучы «Без бергә» МАНО оешмасы һәм волонтерлар көче белән сугышчылар өчен беренче кирәкле җыелмалар җыю оештырылды. 326 мобилизацияләнгән солдат адреслы посылкалар алды. Акча, әйберләр һәм азык-төлек җыюда Шәриев Рафаэль Исмәгыйль улы һәм Шәриева Румия Иршат кызы җитәкчелегендәге «Вьетнам» сәүдә комплексы эшкуарлары коллективы зур ярдәм күрсәтте.

«Зәкят» фонды Казан Башкарма комитеты һәм Казан епархиясе белән берлектә Донецк һәм Луганск качакларына гуманитар ярдәм күрсәтүгә оператив рәвештә кушылды. 2022 елның апрелендә 462 качакка шәхси гигиена һәм көнкүреш химиясе әйберләре җыелмаларын адреслы тарату юлы белән хәйрия ярдәме тапшырылды (ярдәм күләме 310 кг). 2022 елның августында фонд активистлары 150дән артык балага сумкалар һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырды. Бу һәм башка күп кенә яхшы инициативаларны Россия Православие Чиркәвенең Татарстан митрополиясе, Татарстан Республикасы мөселманнары диния идарәсе әйдәп баручы конфессияләренең рухи лидерлары җитәкли һәм мәгърифәтчелек һәм хәйрия акцияләре, хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм оештыра.

Иҗтимагый палата әгъзалары Мөнир Гафиятуллин, Евгений Гибин һәм башкалар мина эзләүче җайланмаларга акча җыюны оештырдылар, шуларның 2сен Татарстанда оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарына тапшырдылар. Шулай ук үз акчаларына 11 очучы өчен 2 җәйге кием комплекты, 60 очучы өчен кышкы кием комплекты сатып алдылар.

Шәхси гражданлык инициативаларын кечкенә гаиләләр һәм шәһәрләр, ветераннар оешмалары һәм мәктәпләр, предприятиеләр һәм югары уку йортлары күрсәтте. Беренче көннәрдән үк мәгълүмат, регламентлаучы документлар, аңлатмалар җитмәгәндә, гражданлык җәмгыяте югары дәрәҗәдә үзүзен оештыру, рух һәм бердәмлек көчен күрсәтте.

Яңа гражданлык практикалары безнең традицион кыйммәтләребезнең тормышчанлыгын күрсәтте. Алар һәркемгә аңлаешлы булган үзара ярдәм һәм кайгырту телен җанландырды, төрле гражданлык җәмгыятьләренең: волонтерлык, фәнни, күрше, корпоратив, студент һәм башка күпләрнең бердәмлегенең нигезе булды.

2022 елда #МыВместе бөтенроссия үзара ярдәм акциясе кысаларында, дәүләтнеке булмаган һәм адреслы характердагы чараларны, хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә психологик, юридик, көнкүреш ярдәме күрсәтүне үз эченә алган «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте эшчәнлеген торгызды. Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» штаблары төзелде, 85 гуманитар ярдәм җыю пункты ачылды. Әлеге инициатива Гомумроссия халык фронтының төбәк бүлекчәләре, «Россия юристлары ассоциациясе», «ОНФ яшьләре», «ДОСААФ», «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, ветераннар һәм эзләнү оешмалары, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, волонтерлык берләшмәләре вәкилләрен берләштерде.

2022 елда Иҗтимагый палата һәм В.Г. Тимирясов исемендәге КИУның «Социаль фикерләү мәктәбе» уртак фәнни-белем бирү проекты эше дәвам итте, аның дискуссия мәйданчыкларында 2022 елгы иҗтимагый консолидация нигезендә җаваплы гражданлык җәмгыятенең үсешенә, әхлакый нормаларга һәм социаль практикаларына юнәлдерелгәнлеге ассызыклана.

Тикшеренү нәтиҗәләре буенча республикада яшәүчеләрнең күпчелеге гамәлдәге дәүләт курсына һәм республика җитәкчелеге карарларына ышаныч белдерде: Владимир Владимирович Путинга ышанучылар – 78,4%; Рөстәм Нургали улы Миңнехановка ышанучылар – 76,8%; муниципаль берәмлек башлыкларына ышанучылар – 59,5%; республикадагы вазгыятьтән канәгать булучылар – 76,2%.

2. Гражданнарның ышанычы – үсешнең иң мөһим ресурсы

2022 елда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына 2520 мөрәҗәгать килде, 2021 елда – 1558. Гражданнарны борчыган төп тема өлешчә мобилизация булды. Шуңа бәйле рәвештә дәүләт органнары, Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, экспертлар берләшмәсе катнашында консультацияләр, кабул итүләр үткәрелде.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына мөрәҗәгать иткәндә башка темалар да билгеләнде.

Торак-коммуналь хуҗалык темасы буенча сораулар каты көнкүреш калдыклары, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә һәм яңадан исәп-хисапларга, идарәче компанияләр һәм торак милекчеләре ширкәтләре эшчәнлегенә, күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен (гомуми файдалану урыннары, йорт яны территориясе, түбә) тотуга, су белән тәэмин итүдә өзеклекләргә, җылытуга, күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен санитар эшкәртү кагыйдәләренә кагылды. Республика халкының торак-коммуналь хуҗалык оешмалары, дәүләт хакимияте органнары һәм бизнес вәкилләре белән цифрлы форматта хезмәттәшлек итү мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан, мобиль кушымта форматында тәкъдим ителгән «Локоло» сервисы булдырылды һәм эшләтеп җибәрелде. 2022 елның 31 апреленә «Локоло»да 274 идарәче компания һәм торак милекчеләре ширкәте теркәлгән иде.

Хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсе административ, җинаять һәм гражданлык суд эшләре өлкәсендә консультацияләр, милеккә кагылышлы бәхәсләр, халыкка юридик консультацияләр һәм аларны бирү сыйфатын үз эченә ала.

Мәгариф өлкәсендә гражданнар урта гомуми белем бирүнең сыйфаты, балаларны тәрбияләү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар җитмәү мәсьәләсе нисбәтеннән борчылалар. Сәламәтлек саклау өлкәсендә күрсәтелә торган медицина хезмәтләренең сыйфаты һәм уңайлылыгы мәсьәләләре күтәрелде. «Шәһәр мохите инфраструктурасы» блогында иң еш очрый торган темалар булып, төзелеш, юл инфраструктурасын ремонтлау, иҗтимагый тирәлекләрне (юллар, парклар, ишегаллары) төзекләндерү мәсьәләләре һәм тәкъдимнәре тора. Шулай ук республика халкы «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» проекты кысаларында әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә актив катнашты. 2022 ел нәтиҗәләре буенча төзекләндерү өчен территорияне сайлауларда 207 мең кеше катнашты.

Сорауларның чираттагы блогы төрле социаль түләүләргә, ташламаларга, шул исәптән яңа законнар һәм көйләүче документлар кабул ителүгә бәйле.

Даими җәмәгатьчелек контроле үзәгенең күз уңында илкүләм проектларның һәм программаларның гамәлгә ашыру, балаларның сәламәтләндерү һәм ял итү эшчәнлеген оештыру, ишегалларын төзекләндерү программалары, торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре, мәгариф оешмаларында «кайнар туклану» оештыру, даруларга бәяләрне мониторинглау, шулай ук халык арасында социологик сораштырулар оештыру һәм үткәрү, гражданлык җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга җәлеп ителүен күзәтү тора.

Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары әгъзалары район башлыкларының коррупциягә каршы тору буенча ярдәмчеләре белән берлектә муниципаль районнарның, шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында халык арасында сораштырулар үткәрделәр. Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары мәгариф өлкәсендә – «Яшь профессионаллар» һәм «Цифрлы белем бирү мохите», демография буенча – «Өлкән буын», «Спорт – тормыш рәвеше», сәламәтлек саклау буенча – «Сәламәтлек саклау», мәдәнияттә – «Мәдәни мохит», торак-коммуналь хуҗалыкта – «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру», муниципаль берәмлекләрдә – «Безнең ишегалды», «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» илкүләм проектларын тормышка ашыруны, районнарда, шулай ук шәһәр халкы өчен социаль яктан әһәмиятле объектларны – гомуми белем бирү мәктәпләрен, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен, күпфатирлы йортларны һ.б. төзү һәм реконструкцияләү барышын мониторинглауда катнашалар.

Мәсәлән, Арча муниципаль районы Иҗтимагый советы әгъзаларының даими контролендә «Безнең ишегалды» республика программасын тормышка ашыру тора (2022 елда 23 күпфатирлы йортның ишегалды һәм 10 ишегалды ремонтланды һәм «Арча шәһәренең Зур урамы» реконструкцияләнде).

Муниципаль районнарның Иҗтимагый советлары әгъзалары мәгариф учреждениеләренең яңа уку елына кабул итү комиссияләре эшендә катнашалар. Азнакай районы Иҗтимагый советының 36 әгъзасы «Заманча мәктәп» – «Үсеш нокталары» илкүләм проектын тормышка ашыруны контрольдә тоту өчен мәктәпләргә бардылар.

Әлмәт районында Иҗтимагый совет әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган 10 иҗтимагый әһәмиятле хокукый актлар һәм башка документлар проектларына, шул исәптән муниципаль программалар проектларына ведомство максатчан программаларына: «Әлмәт муниципаль районында 2021–2023 елларга мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне үстерү» муниципаль программасы проектлары, «Стратегия 2030. Яңа аспектлар», «Әлмәт муниципаль районында күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуны профилактикалауның ведомство программасы»н, шулай ук «2015–2024 елларга Әлмәт муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру» муниципаль программасы буенча үз тәкъдимнәрен керттеләр.

2022 елда Сарман муниципаль районы Иҗтимагый советы әгъзалары «Демография» илкүләм проекты һәм «Гериатрия» профиле буенча медицина ярдәме системасын үстерү кысасында Сарман районында гериатрия кабинетына ай саен килеп, Иҗтимагый совет эшен оештырдылар.

Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары рәисләре һәм әгъзалары сайлау участокларында күзәтүчеләрнең эшен оештыру үзәкләренә әверелделәр һәм үзләре дә сайлауларда күзәтүчеләр һәм сайлау комиссиясе әгъзалары буларак актив катнашалар. Яшел Үзән муниципаль районы Иҗтимагый советы әгъзаларының эш тәҗрибәсе муниципаль районның иң яхшы тәҗрибәсе буларак, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы утырышында тәкъдим ителде.

Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары әгъзалары җәмәгатьчелек тыңлауларында, авыл җирлекләрендә гражданнар җыеннарында, район үзәкләре халкы белән очрашуларда, хезмәт коллективларында, югары уку йортлары, урта махсус уку йортлары студентлары белән очрашуларда актив катнашалар һәм муниципаль хакимият органнары белән алга таба бергә эшләү өчен җәмәгатьчелек тәкъдимнәрен гомумиләштерәләр, моннан тыш, шулай ук закон белән саклана торган зыян китерү куркынычларын профилактикалау, муниципаль берәмлекләр территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль торак контроле кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау; муниципаль районнар территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программа проектларының иҗтимагый фикер алышуларында катнашалар.

2021–2022 елларда Бөгелмә муниципаль районында шәһәрнең үзәк урамнарының берсен төзекләндерү проекты буенча җәмәгать фикер алышулары уздырылды. Җәмәгать тыңлаулары вакытында Бөгелмә муниципаль районы Иҗтимагый советы әгъзалары, халык, активистлар, эшмәкәрләр, Муса Җәлил урамында урнашкан җир кишәрлекләре һәм биналарның милекчеләре һәм арендаторлары үзәк сулык янындагы территорияне төзекләндерү концепциясе буенча үз тәкъдимнәрен җиткерделәр.

Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары яшьләр белән һәм Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары оешмаларында, предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә яшьләр хәрәкәтен активлаштыру чаралары буенча эш алып баралар, шулай ук балалар һәм яшүсмерләрне патриотик рухта тәрбияләү буенча эш алып барыла. Муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары әгъзалары гомуми белем бирү мәктәпләренең ата-аналар җыелышында укучыларны укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләре буенча чыгышлар ясыйлар. Мәсәлән, «Тормыш дәресләре» тәрбия проекты кысаларында Мөслим муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе Рушат Солтанов Мөслим гимназиясендә һәм Г. Тукай исемендәге урта белем бирү мәктәбендә атна саен «Рушат укулары» дәресләре үткәрә. Шулай ук Мөслим лицее, Баек, Олы Чәкмәк, Күбәк урта белем бирү мәктәпләре укучылары белән очрашулар оештырылды.

Иҗтимагый советларның игътибары шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә мәгариф, сәламәтлек саклау, ТКХ өлкәсендә коррупциягә каршы тору, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында газлаштыру мәсьәләләре буенча тематик кайнар линияләр үткәрүгә юнәлтелде, шулай ук Иҗтимагый совет рәисләре һәм әгъзалары даими нигездә гражданнарны кабул итә.

2022 елның хисап чорында Саба районында Иҗтимагый совет рәисе Фәрит Зарипов 31 гражданны кабул итте. Мөрәҗәгатьләрнең төп темалары: төзелеш мәсьәләләре буенча – 11%, торак белән тәэмин итү – 29%, халыкны социаль тәэмин итү – 35%, мәгариф – 6%, җир мөнәсәбәтләре – 8%, сәламәтлек саклау – 4%, эшкә урнашу – 7%.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында республикада мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирелә. Үз эшчәнлекләрендә муниципаль районнарның барлык Иҗтимагый советлары мәдәният, мәгариф өлкәсендәге оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәя бирү буенча эшне оештыруга аерым игътибар бирәләр. Ел саен мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмаларның исемлеге билгеләнә, анда халыкка хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты буенча тикшеренү үткәреләчәк. Бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча тикшерелә торган учреждениеләрдә хезмәт коллективлары җыелышлары үткәрелә, ачыкланган кимчелекләрне һәм хокук бозуларны төзәтү буенча план төзелә, шулай ук халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту буенча Иҗтимагый советларның тәкъдимнәре бирелә.

Җәмәгатьчелек контролен көчәйтү, бердәм хокукый кыр булдыру максатларында муниципаль берәмлекләргә «Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында»гы (21.07.2014 ел) 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен үтәү максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең Иҗтимагый советы турындагы нигезләмәне үз эшләрендә кулланырга тәкъдим ителде. Нигезләмәгә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасының эксперт нәтиҗәләре алынды. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы муниципаль берәмлекләр башлыкларына үрнәк нигезләмә җибәрде. Шулай итеп, Яшел Үзән, Актаныш һәм Түбән Кама районнарында муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары турында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән нигезләмә буенча иҗтимагый советлар формалаштыруга керештеләр.

2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль бүлекчәләре каршында 38 Иҗтимагый совет эшләде, шул исәптән 31е – Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары каршында һәм 7се – Россия Федерациясе территориаль башкарма хакимият органнары каршында.

Үткәрелгән анализ күрсәткәнчә, министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның Иҗтимагый советлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында»гы 2010 елның 18 ноябрендәге 906 нчы номерлы карарына ярашлы рәвештә эшлиләр. Россия Федерациясе территориаль башкарма хакимият органнарының Иҗтимагый советлары ведомство норматив хокукый актларына ярашлы эш итә. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Иҗтимагый советлары составы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә өч елга бер тапкыр формалаштырыла. Мәгариф, мәдәният, социаль яклау һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә 40 оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советлар тиешле министрлыкларда аерым структуралар буларак төзелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында»гы 2010 елның 18 ноябрендәге 906 нчы номерлы карарына һәм министрлыкларның, ведомстволарның һәм дәүләт комитетларының Иҗтимагый советлары турындагы нигезләмәләренә ярашлы рәвештә, Иҗтимагый совет утырышлары елына дүрт тапкырдан да ким үткәрелмәскә тиеш. Дәүләт хакимияте органнары биргән мәгълүмат буенча, бу норманы барысы да үтәми. Башкарма хакимиятнең түбәндәге органнары һәм ведомстволары каршында Иҗтимагый советларның дүрттән дә кимрәк утырышы үткәрелде: Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы (2), Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы (1), «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы (1), Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы (1), Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (3).

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы Иҗтимагый советларның эшчәнлеге җитәрлек яктыртылмый. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы 26 февральдә дәүләт хакимияте башкарма органнарына Иҗтимагый советлар турындагы мәгълүматны актуальләштерүдә һәм аларның эшчәнлеген даими яктыртуда ярдәм итүне сорап хат җибәрде. Әлеге эшнең нәтиҗәсе чыннан да министрлык һәм ведомство сайтларында урнаштырылган Иҗтимагый советлар битләрендәге мәгълүматны актуальләштерү булды. Шул ук вакытта бер елдан соң бу юнәлештә кабаттан җитәрлек эш булмавы ачыклануын да билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында уздырылган дүрт утырышның 22 июльдә булганына гына беркетмә урнаштырылган, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы буенча бер генә утырыш беркетмәсе дә юк. Иҗтимагый совет эше Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе тарафыннан даими яктыртыла.

Иҗтимагый контроль субъектларының әлеге эшчәнлектә катнашу нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына Иҗтимагый совет утырышларын елына дүрт тапкырдан да сирәгрәк үткәргәннәргә ярдәм күрсәтергә һәм үз рәсми сайтларында Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүматны, шул исәптән утырышлар беркетмәләрен даими урнаштырырга тәкъдим итәбез.

«Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының (29.03.2013 ел) 214 нче карарына ярашлы рәвештә, алар әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмаганлыктан, министрлыкларның иҗтимагый советлары тарафыннан даими нигездә норматив-хокукый актлар проектларын тикшерү буенча эш алып барыла. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Иҗтимагый советы тарафыннан «Татарстан Республикасында электр двигательләре белән транспорт чаралары өчен зарядлы инфраструктураны үстерү» дәүләт программасын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Иҗтимагый советы тарафыннан «2014–2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты каралды.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе танылган иҗтимагый институтларның берсе булды.

2022 елда бишенче чакырылыш эше тәмамланды. Аның составына 8 коммерциячел булмаган оешма вәкилләре керде.

Комиссия тарафыннан төрмәдән азат ителгән гражданнар һәм аларның туганнары өчен даими эшләүче кайнар линия оештырылды. 2022 елда һәр сишәмбе «НКО Йорты» базасында төрмәдә утыручы гражданнарның туганнарын кабул итү үткәрелде, тоту шартлары, җәзаны җиңелрәк җәзага алмаштыру, гамәлдәге законнарны аңлату мәсьәләләре буенча 128 кеше кабул ителде.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе рәисе һәм әгъзалары Прокуратура һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында даими рәвештә Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләренең вакытлыча тоту изоляторларына һәм махсус кабул итү бүлмәләренә, муниципаль берәмлекләрнең полиция бүлекләренә барып кайтты.

2020 елдан 2023 елга кадәр төзәтү учреждениеләренә 370тән артык бару оештырылды, шулай ук 14 тапкыр РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Академик В.М. Бехтерев исемендәге интенсив күзәтү белән махсуслаштырылган типтагы Казан психиатрия хастаханәсенә (стационары) барылды. Барган вакытларда гражданнарның 1500дән артык мөрәҗәгате каралды.

Төзәтү колонияләренә барганда, закон билгеләгәнчә, хөкем ителгәннәрне учреждениеләрдә тоту шартларына аерым игътибар бирелә. Шулай ук тулай тораклар, ашханәләр, җитештерү цехлары, медицина бүлекләре, инвалидлар өчен отрядлар, катгый шартлы тоту отрядлары, штраф изоляторлары һәм камера тибындагы биналар каралды. Мәҗбүри тоту урыннарына бару кысаларында торак зоналары каралды, анда хөкем ителгәннәр белән әңгәмәләр үткәрелде яки хөкем ителгәннәрнең шәхси мәсьәләләре буенча комиссия кабул итте. Һәр кабул итү вакытында ТР Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзаларына 50гә кадәр кеше мөрәҗәгать иткән.

Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары гражданнарны мәҗбүри тоту урыннарында килеп туган конфликтлы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашалар.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе арасында күп еллар дәвамында конструктив хезмәттәшлек җайга салынды. Мондый динамика җәзаларны үтәү системасының ачыграк булырга омтылышын исбатлый.

Шулай ук Татарстанның Иҗтимагый күзәтү комиссиясе адресына Россиянең башка субъектларында яшәүче гражданнар да мөрәҗәгать итә. Башка төбәкләрнең җәмәгатьчелек күзәтү комиссияләре белән тыгыз хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә мондый мөрәҗәгатьләр оператив рәвештә эшкә алына.

Моннан тыш, Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары коммерциячел булмаган оешмалар белән берлектә хөкем ителгәннәр өчен чаралар үткәрә. Татарстан Республикасының «Халык сәламәтлеген саклау һәм социаль яктан тискәре күренешләрне кисәтү өлкәсендә профилактика һәм инициатива» төбәк бүлеге 2 нче һәм 19 нчы төзәтү колонияләрендә алкоголь һәм наркотикларга бәйле рәвештә хөкем ителгәннәр өчен тернәкләндерү төркемнәре ачты, «Юридик клиника» төбәк бүлеге чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен консультацияләр үткәрә. «Социаль реабилитация һәм адаптация үзәге» коммерциячел булмаган оешмасы ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү буенча эш алып бара: вакытлыча торак бирелә, бушлай юридик һәм психологик ярдәм күрсәтелә, эшкә урнашуда, документларны торгызуда, шәһәрара һәм халыкара билетлар, шулай ук БДБ илләренә билетлар сатып алуда, алкогольгә бәйлелектән котылуда ярдәм күрсәтелә.

2022 елның 23 августында «Берләшмә» форумы кысасында Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясенең яңа составына кандидатлар өчен укыту семинары узды, чарада Татарстанның 20дән артык төрле коммерциячел булмаган оешмаларыннан 21 кеше турыдан-туры һәм 39 кеше онлайн катнашты. Чарада РФ Иҗтимагый палатасының куркынычсызлык һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек комиссиясе рәисе Александр Воронцов, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков катнашты.

Иҗтимагый күзәтү комиссиясе составына кандидатлар тәкъдим итү процедурасы башланганнан соң, Татарстан Иҗтимагый палатасы үзенең тәкъдимнәрен яңа составка җибәрде. Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы советының 2022 елның 26 сентябрендәге карары белән Иҗтимагый күзәтү комиссиясенең яңа алтынчы составы формалаштырылды: җәмәгатьчелек вәкилләре саны 11 дән 18 кешегә кадәр артты. Яңа составка элекке состав әгъзалары да, яңа җәмәгать эшлеклеләре дә керә: актив гражданлык позициясенә ия битараф булмаган гражданнар, 11 социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма һәм төрле дини конфессия вәкилләре.

2022 елның 19 октябрендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева тантаналы шартларда Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясенең алтынчы состав әгъзаларына мандатлар тапшырды. Рәсми өлештән соң алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясенең беренче утырышы узды, анда бертавыштан Иҗтимагый күзәтү комиссиясе рәисе – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы Азат Гайнетдинов сайланды, комиссия регламенты кабул ителде. Чарада шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе, ТР Прокуратурасы, ТР Эчке эшләр министрлыгы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре катнашты.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары эшендә дә, республика башкарма хакимияте органнары каршындагы советлар эшендә дә актив катнашалар.

Икътисад һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеге инфраструктурасы мәсьәләләре буенча комиссия әгъзалары Кукмара муниципаль берәмлегенең торак пунктлары чикләрен билгеләү буенча комиссия утырышында, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны күзәтү буенча эшче төркеме эшендә, Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитетының кайбер утырышларында, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының коррупциягә каршы чаралар, кече һәм урта эшмәкәрләргә ярдәм итү буенча киңәшмәләрдә, Аксубай районындагы сайлауларга җәмәгатьчелек контроле чараларында, кече һәм урта бизнес субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча ведомствоара эшче комиссия утырышында катнаштылар.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль мәсьәләләр һәм хәйриячелек буенча комиссиясе әгъзалары Татарстан Республикасы Дәүләт Советының социаль сәясәт комитеты утырышларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты эксперт советы эшендә, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Сәнәгать һәм сәүдә министрлыклары каршындагы Иҗтимагый советта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә, балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе эшендә, Иҗтимагый күзәтү комиссиясендә, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Т.П. Ларионова җитәкчелегендә республикада илкүләм проектларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат комиссиясе утырышларында катнаштылар.

2022 елның гыйнварында мәгариф һәм фән буенча комиссия тарафыннан социаль икътисадый һәм гуманитар дисциплина укытучыларының югары уку йортлары арасындагы координация советы эше кысасында методологик республика семинарлары оештырылды. Семинарлар программасы үз эченә җәмгыятьнең социаль-икътисадый үсешенең актуаль мәсьәләләре буенча танылган галимнәр, сәясәтчеләр, дәүләт хезмәткәрләре белән очрашуларны ала.

Мәгариф һәм фән комиссиясе «Менталь сәламәтлек» иҗтимагый проекты эшенә актив кушылды. 2022 елның февралендә проектның эшче төркеме оештырылды, аңа мәгариф һәм фән буенча комиссия рәисе А.В. Тимирясова керә. 2022 елның октябрендә мәгариф оешмаларының инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту һәм тәрбияләүне оештыру өлешендә мәгариф өлкәсендә законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәвен күзәтү өчен мәгариф оешмаларына чыгулар узды. Сыйфатлы һәм уңайлы белем алуга балаларның хокукларын тәэмин итү, яклау һәм аутизм спектры бозылулары булган балаларга белем бирү шартларын тикшерү максатларында, Казанда – 29 нчы прогимназиядә, 168, 97, 86, 51 нче мәктәпләрдә, Әлмәт шәһәрендә – 21 нче мәктәптә, инженерлык лицеенда, Түбән Кама шәһәрендә – 21 нче мәктәптә һәм 37 нче күппрофильле лицейда, Яр Чаллыда – 3 һәм 53 нче мәктәпләрдә мониторинг үткәрелде. Мониторинг үткәрү нәтиҗәсендә физик кимчелекле балалар өчен ресурс сыйныфлары эшен оештыру буенча киңәшләр эшләнде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Республика ата-аналар советы Мәгариф һәм фән комиссиясе белән берлектә эшли. Советны Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эксперты Н.В. Фролова җитәкли. Совет эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе – җәмәгатьчелек контроле. 2022 ел дәвамында кайнар ризык белән туклануның сыйфатын контрольдә тоту буенча актив эш алып барылды. Контрольне оештыру уңайлы булсын өчен, совет тарафыннан эш дәфтәре һәм туклану сыйфатын контрольдә тоту журналы эшләнә, бу ата-аналарның әлеге эштә катнашуын киңәйтергә мөмкинлек бирә. Узган уку елында совет тарафыннан мәктәп ашханәләренә 2777 ата-ана рейды оештырылды, 2020/2021 елларда 2562 булган. Бу гамәл социаль челтәрләрдә һәм ата-аналар җыелышларында ата-аналарның шикаятьләрен киметергә; туклану оешмасы белән килештерергә һәм конструктив диалог алып барырга өйрәнергә; ризыкның эстетик бирелүен үзгәртергә; ата-аналарның мәктәп пешекчеләренә нигезсез дәгъваларын киметергә, контролерлар түгел, ә ярдәмчеләр булырга; «ашханәдә начар ашаталар» дигән стереотипны үзгәртергә мөмкинлек бирде.

Комиссия әгъзалары ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән берлектә Казан, Түбән Кама, Азнакай, Аксубай, Нурлат, Чирмешән һәм башка районнарда укучыларның кайнар ризык белән туклану сыйфатын җәмәгать тикшерүе чараларында катнаштылар. Эш нәтиҗәсендә балаларның туклануын яхшырту буенча белем бирү оешмаларына тәкъдимнәр ясалды. Комиссия эшенең тагын бер юнәлеше – совет белән берлектә мәктәпләрне ремонтлау яки төзү барышына җәмәгатьчелек контроле.

2022 елда мондый формадагы контроль Яр Чаллы, Әлмәт, Чүпрәле, Тукай, Балык Бистәсе, Алексеевск, Мөслим, Ютазы, Югары Ослан районнарында 27 мәктәптә мәктәп үзидарәсе вәкилләре белән берлектә гамәлгә ашырылды.

Комиссия әгъзалары шулай ук кышкы, язгы һәм җәйге каникуллар чорында мәктәп яны лагерьлары һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре эшенә иҗтимагый контроль чараларында актив катнаштылар. Нәтиҗәдә, белем бирү оешмалары адресына балаларга өстәмә белем бирү программаларын камилләштерү, сыйныф җитәкчеләренә, студентларның академик төркемнәренең кураторларына түләүләрнең тулылыгын һәм срокларын үтәү, балаларны тәрбияләүче гаиләләргә дәүләт гарантияләре һәм түләүләр бирү, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны БДИ формасында әзерләү һәм йомгаклау аттестациясе программалары тәкъдим ителде.

Ел дәвамында комиссия әгъзалары Мәгариф һәм фән, Спорт, Яшьләр эшләре, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыкларның Иҗтимагый советлары эшендә; Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышларында, мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август киңәшмәсе пленар утырышында, Россия Дәүләтнеке булмаган югары уку йортлары ассоциациясенең киңәйтелгән утырышларында, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы утырышында, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы каршындагы Иҗтимагый советның мәктәпләрне капиталь ремонтлау һәм мәктәп инфраструктурасын үстерү мәсьәләләре буенча иҗтимагый контроль федераль һәм төбәк штабларының киңәйтелгән утырышларында; «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» республика хәйрия акциясендә, ата-аналар интернет-җыелышында, Татарстан Республикасының цифрлы үсешенә ярдәм итү ассоциациясе конференциясендә катнаштылар.

4. Коммерциячел булмаган сектор – үсеш мөмкинлекләре

Республикада коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча системалы эш «Татарстан Республикасында 2014–2025 елларга социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү» ярдәмче программасы кысаларында программа ысулы нигезендә башкарыла, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында»гы 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган.

Аның максаты – коммерциячел булмаган оешманың социаль юнәлешле эшчәнлеген һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә аларның катнашуын стимуллаштыру, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ килешүне саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын арттыру, дәүләт һәм җәмәгать мәнфәгатьләренең тигезлеге нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү.

Әгәр программаны гамәлгә ашыруның беренче елларында төп бурыч коммерциячел булмаган сектор һәм социаль эшкуарлык булдыру булса, бүген бу секторның сыйфатлы үсеше актуаль.

Коммерциячел булмаган сектор гомумдәүләт бурычларын хәл итүдә әһәмиятле көчкә әверелде инде. Ә пандемия сынаулары вакытында, хакимият органнары тарафыннан берьюлы күп кенә стратегик мәсьәләләрне хәл итү кирәклеге, 2022 елдагы кебек, коммерциячел булмаган оешмаларның, гражданнарның иҗтимагый берләшмәләренең дәүләтнең ышанычлы һәм алыштыргысыз партнерлары булуын тагын бер кат исбатлады. Алар җәмгыятьнең сорауларына беренче булып җавап бирәләр.

2022 елның 28 февралендә Россиянең иң эре коммерциячел булмаган оешмалары лидерлары һәм активистлары «Президент һәм ил белән бергә!» дигән ачык мөрәҗәгать бастырды, аны республикабызның коммерциячел булмаган секторы актив рәвештә хуплады. Мәсәлән, «Ватан уллары» оешмасы, «Сугышчан туганлык» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы бүлекчәсе, Казан шәһәренең Яшьләр

tatmitropolia.ru

Ахыры 6 нчы биттә >

парламенты, Татарстан Бакчачылар берлеге, ТР «Яшьләр үсеше» төбәк бүлеге, ТР Яңа Чишмә муниципаль районы хатын-кызлар советы берләшмәсе һәм башкалар.

Коммерциячел булмаган оешмалар, үзләренең төп устав бурычларыннан тыш, җәмгыятькә кирәк булган максатлар һәм бурычлар өчен, азат ителгән территорияләргә, анда яшәүче кешеләргә, качакларга, мобилизацияләнгәннәргә, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләргә ярдәм итәргә әзер. Мондый нәтиҗәне күреп, дәүләт, Донбасс һәм Украина территорияләреннән килгән кешеләргә ярдәм күрсәтү, Донбасста социаль, хәйрия, мәгариф, мәгърифәтчелек, экологик проектларны гамәлгә ашыру Президент грантлары фонды, Президентның мәдәни инициативалар фонды кысаларында махсус бәйгеләр үткәреп, аларга булыша.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында»гы 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1002 номерлы Указы нигезендә 2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантларын тапшыру буенча Бердәм бәйге үткәрелде. Указны үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирү бәйгеләрен үткәрү буенча республика комиссиясе расланды, бердәм грант операторы билгеләнде. Республика комиссиясе составының яртысыннан артыгы күренекле җәмәгать эшлеклеләре, гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатлары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре.

Бәйгедә 21 социаль әһәмиятле юнәлеш буенча кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар катнашты.

Бәйгегә барлыгы 420 гариза бирелгән. Бәйгедә беренче тапкыр Татарстан Республикасының 45 муниципаль берәмлегеннән, шулай ук Россия Федерациясенең 20 башка субъектыннан коммерциячел булмаган оешмалар катнашты. Республиканың 41 муниципаль берәмлегеннән һәм Россия Федерациясенең 16 субъектыннан 230 НКО җиңүче булды. Проектларны түбән бәяләү сәбәпле, экспертлар Әтнә, Биектау, Лениногорск, Ютазы районнарыннан коммерциячел булмаган оешмалар гаризаларын үткәрмәде.

Беренче мөһим нәтиҗә – Татарстанның барлык муниципаль берәмлекләреннән коммерциячел булмаган оешмаларның катнашуы.

Республикада хәзерге вакытта 6106 коммерциячел булмаган оешма теркәлгән, шуларның 1712се – иҗтимагый берләшмәләр. 1247 ирекле берләшмә эшли, аларда – 138165 волонтер. Коммерцияле булмаган оешмаларның 40 процентка якыны Казанда теркәлгән.

Шуңа күрә үсеш резервларының берсе булып Татарстан муниципаль берәмлекләрендә коммерциячел булмаган оешмалар (НКО) санын һәм аның сыйфатлы үсешен арттыру тора. Моның өчен Татарстан районнарында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча 51 ресурс үзәгенә бәйге нәтиҗәләрен анализлау, шулай ук республика муниципаль берәмлекләренең Иҗтимагый советларының НКО белән эшен анализлау мөһим.

Бу бурыч коммерциячел булмаган оешма проектларына акча алуның киң мөмкинлекләре һәм проектларның инновациялелегенә, проект бюджетын нигезләүгә таләпләрнең артуына бәйле рәвештә актуальләшә.

2022 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасына иҗтимагый һәм коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан грант акчалары җәлеп ителгән:

– Президент грантлары фонды – 192 млн 308 мең (2021 – 138 млн 770 мең) сум;

– Мәдәни инициативалар фонды – 84 млн 787 мең (2021 – 50 млн) сум;

– Росмолодежь – 68 млн 61 мең сум;

– ирекле хәрәкәткә ярдәм итү өчен субсидияне республика инде дүртенче ел рәттән 7,6 млн сум күләмендә ала.

2022 елда Президент грантлары фонды бәйгесе кысасында Татарстан Республикасыннан 584 гариза бирелгән, шуларның 99ы 192308133 сумлык ярдәм алган. 65 проектны – Казан шәһәреннән коммерциячел булмаган оешмалар, ә 34 проектны республиканың башка муниципаль берәмлекләреннән (Чаллы шәһәре (5), Әгерҗе (1), Арча (1), Баулы (1), Бөгелмә (1), Буа (1), Чүпрәле (1), Алабуга (3), Яшел Үзән (3), Кукмара (1), Лениногорск (1), Мамадыш (1), Менделеевск (1), Түбән Кама (6), Яңа Чишмә (3), Питрәч (2), Спас (1), Тукай (1) районнары) тәкъдим иткәннәр.



Узган ел белән чагыштырганда 2022 елда Президент грантлары фонды бәйгесендә Татарстан Республикасыннан гаризалар саны 2,5 процентка кимеде (2021 елда – 599), җиңүчеләр саны 5 процентка артты (2021 елда – 4), ярдәм суммасы 27,8 процентка артты (2021 елда – 138770446 сум).



Җәлеп ителгән грант акчалары суммалары «Регион-НКО» өченче секторының төбәк рейтингында исәпкә алына.

Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы тарафыннан РАЭКС Аналитика рейтинг агентлыгы белән партнерлыкта төзелгән 2022 ел рейтингы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы 4 нче урынны алды һәм түбәндәге номинацияләрдә Россия Федерациясенең иң яхшы төбәкләре исемлегенә керде:

– коммерциячел булмаган сектор масштабы буенча топ – 3;

– төбәк өчен коммерциячел булмаган оешманың икътисадый әһәмияте буенча топ – 3;

– коммерциячел булмаган оешмаларны яклау ресурс үзәкләре һәм РОП институциональ мәйданчыклары әһәмияте буенча топ – 5;

– төбәк өчен социаль юнәлешле НКОның социаль әһәмияте буенча топ–10;

– төбәктә коммерциячел булмаган оешма секторын эксперт бәяләве буенча топ–10.

«Регион-НКО» рейтингының беренче ике чыгарылышында төбәк иҗтимагый палаталары гомуми күрсәткечләр кысаларында бәяләнде. Дискуссияләр барышында еш кына төбәк иҗтимагый палаталары рейтингын аерым проектка бүлү тәкъдиме яңгырады, чөнки төбәк иҗтимагый палаталар функцияләре киңрәк. Төбәк иҗтимагый палаталары шулай ук хокукый актларга экспертиза үткәрәләр, законнар булдыру эшчәнлегендә катнашалар, сайлауларда күзәтү оештыралар һәм башкалар. Шуңа күрә 2022 елда төбәк Иҗтимагый палаталарының беренче рейтингы үткәрелде, анда Татарстан Республикасы Россиядә икенче урынны алды. Татарстан Республикасы законнар булдыру активлыгында топ–10 рейтингында икенче урында тора, медиаактивлык буенча топ–10 рейтингында өченче урында тора, экспертлар фикеренчә, лидерлар унлыгына керә.

Зур нәтиҗәләргә ирешү өчен, «Регион-НКО 2022» өченче секторының төбәк рейтингында республика топ–20 төбәкләргә кермәгән критерийларга игътибар итәргә кирәк:

– «НКОны яклау турында онлайн мәгълүматның булуы»,

– «НКО белән медиаактивлык».

Әлеге юнәлешләрдә көчәйтелгән эш Татарстан Республикасының 6 муниципаль берәмлегендә (Казан, Чаллы, Әлмәт, Чистай, Кукмара, Буа) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәкләре өчен өстенлекле булырга мөмкин. Бу сорауларны эшләү шулай ук коммерциячел булмаган секторны цифрлы үзгәртүдә ярдәм итәчәк.

Грант акчаларының суммасы буенча коммерциячел булмаган сектор резервларының зур булуы күренә. Республикага грант акчаларын җәлеп итүдән тыш, коммерциячел булмаган оешмалар дәүләт хезмәтләрен гамәлгә ашыруда да катнаша.

Үзенең мөрәҗәгатендә ТР Президенты Р.Н. Миңнеханов: «Дәүләтнеке булмаган сектор үсешенә, бигрәк тә социаль өлкәдә ярдәм итү – безнең өстенлекләр арасында», – дип билгеләп үтте.

Коммерциячел булмаган сектор белән партнерлык ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерылгысыз үзенчәлеге булып тора, анда коммерциячел булмаган оешмалар балаларда, яшүсмерләрдә һәм өлкәннәрдә дөньяга экологик караш формалаштырырга, экологик-агарту лекцияләре үткәрергә, территорияләрне төзекләндерергә һәм агачлар утыртырга ярдәм итә.

Иҗади индустрия һәм яңа мәдәният проектлары коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан үстерелә, һәм бу Мәдәният министрлыгы эшендә яңа форматлар ачарга ярдәм итә. ТР Яшьләр эшләре министрлыгының мөһим проектлары коммерциячел булмаган оешмалар һәм волонтерлык берләшмәләре белән дә гамәлгә ашырыла. Мәгариф һәм фән министрлыгы эшендә мөһим компонент булып ата-аналар берләшмәсе тора. Ирекле янгын сүндерү дружиналары, эзләү-коткару отрядлары Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән хезмәттәшлектә зур тәҗрибәгә ия.

Татарстан Республикасында социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы дәүләтнеке булмаган оешмаларның 2021–2024 елларга халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчаларына этаплап керүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы нигезендә (Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Т.А. Голикова тарафыннан расланган 11.12.2020 № 11826п – П44) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмалар челтәре оештырылды һәм үстерелә, аларга ярдәм итү инструментлары билгеләнде.

Федераль законнарны үтәү максатыннан, 2015 елдан коммерциячел булмаган оешмаларга социаль хезмәтләрне тулы хокуклы тәэмин итүчеләр булырга һәм аларны күрсәткән өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләүләре алырга мөмкинлек бирә торган норматив хокукый база формалаштырылган. Болар түбәндәгеләр:

– персоналга, матди-техник җиһазлануга, хезмәт күрсәтү тәртибенә һәм шартларына, сыйфат күрсәткечләренә һәм социаль хезмәт күрсәтүнең 56 нәтиҗәсен бәяләүгә дәүләтнеке дә, дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләргә карата да таләпләр унификацияләнгән;

– Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган расланган тәртипкә ярашлы рәвештә социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестры формалаштырылган;

– ел саен халыкка хезмәт күрсәтүче дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларга социаль хезмәт күрсәтүгә бердәм тарифлар билгеләнә;

– дәүләтнеке булмаган оешмаларга субсидия рәвешендә грант бирү шартлары һәм механизмы билгеләнгән.

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән дәүләтнеке булмаган тәэмин итүчеләр саны 2015 елдан бирле 8 тапкырдан артык артты (2022 елда – 26 оешма, 2021 елда – 26 оешма, 2020 елда – 26 оешма, 2019 елда – 24 оешма, 2018 елда – 19 оешма, 2017 елда – 13 оешма, 2016 елда – 8 оешма, 2015 елда – 3 оешма).

2015 елдан социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең гомуми санынннан дәүләтнеке булмаган оешмаларның өлеше 2,3 проценттан 18,6 процентка кадәр артты (2022 елда – 18,6 процент, 2021 елда – 18,4 процент, 2020 елда – 18,2 процент, 2019 елда – 16,9 процент, 2018 елда – 13,7 процент, 2017 елда – 9,7 процент, 2016 елда – 6,2%, 2015 елда – 2,3%).

2022 елда социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына 26 дәүләтнеке булмаган оешма кертелгән (шул исәптән 17 социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма (СОНКО). 2022 елда 12,3 мең кеше дәүләтнеке булмаган секторның социаль хезмәтләреннән файдаланды (дәүләтнеке булмаган оешмаларга 282,96 млн сум күләмендә компенсация түләнде).

Бүген иң зур өлешне яки 77 процентны (20 оешма), социаль хезмәтләргә ихтыяҗ иң югары булган инвалид гражданнарның социаль яктан иң зәгыйфь категорияләренең берсенә реабилитация хезмәтләре күрсәтүче оешмалар тәшкил итә. Мәсәлән, 2022 елда дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан әлеге категориядәге гражданнарның 42 проценты (5,8 мең кеше) һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалидларның 38 проценты (6,2 мең кеше) социаль хезмәтләр күрсәтүне сорап, реабилитация учреждениеләренә мөрәҗәгать иткән.

Республикада дәүләтнеке булмаган оешмалар хезмәт күрсәтә торган гражданнарның чираттагы категориясе – өлкән яшьтәге гражданнар. Бүген коммерцияле булмаган оешмалар «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын кертүдә актив катнашалар.

Социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның үсешенә йогынты ясаучы мөһим фактор булып, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле ролен арттыру һәм учреждениеләр һәм алар күрсәткән хезмәтләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү системасын эшләү тора. Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указына ярашлы рәвештә тармакта күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү системасы кертелә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет карары буенча 2022 елда 53 социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтүче һәм социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кергән 6 дәүләтнеке булмаган оешмада сыйфатка бәйсез бәя бирелде.

Дәүләтнеке булмаган сектор белән бергә эшләү тәҗрибәсе шуны күрсәтте: дәүләтнеке булмаган оешмалар мохтаҗ гражданнарга квалификацияле кадрлар һәм кирәкле җиһазлар белән грамоталы һәм профессиональ рәвештә кирәкле ярдәм күрсәтә ала. Дәүләтнеке булмаган секторга, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга дәүләт финанс ярдәменнән тыш, Татарстан Республикасында шулай ук милек ярдәме күрсәтелә. Бу – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага түләүсез нигездә яки дәүләт (муниципаль) милкендә булган мөлкәтне (күчемле һәм күчемсез милек) ташламалы бәяләре буенча тапшыру.

Хәзерге вакытта 11 социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага (социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән тәэмин итүчеләр реестрындагы оешмаларның гомуми санының 65 проценты (17 оешма) гомуми мәйданы 11,5 мең кв. м булган биналар түләүсез файдалануга тапшырылган.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән дәүләтнеке булмаган оешмалар дәүләт оешмалары белән беррәттән түләүсез «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру» өлешенә керү хокукына ия.

Болар барысы да социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр эшчәнлегенең бизнес-процессларын цифрлаштыруны һәм максималь автоматлаштыруны тәэмин итә, шул исәптән бу түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә:

– социаль хезмәтләр алучыларның шәхси эшләрен электрон рәвештә алып барырга;

– күрсәтелгән хезмәтләрне исәпкә алырга, күрсәтелгән хезмәтләр өчен исәпләүләр һәм финанслауны башкарырга;

– социаль хезмәтләр күрсәтү буенча кирәкле хисапларны автомат рәвештә формалаштырырга;

– архивлаштырырга һәм сакларга.

Моннан тыш, мәгълүмати продукт дәүләт органнарына хезмәт күрсәтү буенча дәүләтнеке булмаган оешмаларның эшчәнлеген онлайн режимда башкарырга мөмкинлек бирә:

– хезмәт күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тоту;

– хезмәт күрсәтүнең вакытында, оперативлыгын, конкрет социаль хезмәт алучыга хезмәт күрсәтүнең тулылыгын анализлау аша;

– оешмага турыдан-туры кермичә хезмәт күрсәтүләрнең санын, срокларын күрсәтүләр, җан башына уртача керем күләмен билгеләүнең дөреслеге, хезмәтләр өчен түләү күләме һәм башкалар.

Бүген Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторны җәлеп итү һәм үстерү өчен барлык шартлар тудырылган, бу социаль хезмәтләр базарын үстерүгә ярдәм итә һәм аларның сыйфатын һәм уңайлылыгын арттырырга, гражданнарыбызның сорауларына туры китереп күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең киң спектрын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Коммерциячел булмаган оешмаларның һәм муниципаль хакимият органнарының үзара эшчәнлегенең заманча үрнәге булып, «Игелекле Казан» коммерциячел булмаган оешмасының яңа эш киңлеген ачу тора. Сеченов урамындагы колл-үзәк һәм конференцияләр залы белән коворкинг 506 кв. м мәйданны били, бер үк вакытта кабинетларда 24 коммерциячел булмаган оешма вәкиле эшли ала. Ул яхшы транспорт юлы булган районда урнашкан, янәшәдә җәмәгать транспорты тукталышы бар, шуңа күрә ата-аналарга һәм пенсионерларга аңа барып җитү җиңел. Яңа урын уңайлы мохит принципларына туры килә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр дә коворкингка йөри ала.

«Игелекле Казан» оешмасы һәм башка хәйрия фондлары мастер-класслар, семинарлар, игелекле кешеләр белән очрашулар һәм башка чаралар үткәрә.

Эчке эшләр белән бер үк вакытта «Безнең ишегалды» программасы буенча янәшәдәге территория төзекләндерелде, физик мөмкинлекләре чикле балалар өчен уен мәйданчыгы төзелде.

Бу тәҗрибә Татарстан муниципаль берәмлекләрендә дә, Казанда да алга таба тарату өчен үрнәк булып тора ала.

Коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм кысаларында ТР Иҗтимагый палатасы тарафыннан берничә чара үткәрелде. 9 февральдә ТР дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм ТР муниципаль хезмәткәрләре өчен семинар кысаларында дәүләт идарәсе югары мәктәбендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе З.Р. Вәлиева «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма һәм муниципаль берәмлекләрне үстерүдә Иҗтимагый советларның роле» дигән лекция укыды.

22 февральдә инновацион үсеш һәм технологияләр трансферы үзәге һәм Казан (Идел буе) федераль университеты Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ярдәме белән «Грант отмас өчен ничек эшләргә?» дигән очрашу үткәрде. Үзәк җитәкчесе А.Г. Дыганов социаль проектларны гамәлгә ашыру өчен грантлар алу ихтималын киметүче төп хаталар турында сөйләде. Грантка гариза әзерләү мәсьәләләре, типик хаталар каралды.

21 октябрьдә Татарстан Иҗтимагый палатасы «Ярдәм үзәкләре буенча сәяхәт» проектында катнашучыларны кабул итте. Бу проект Казан шәһәрендә социаль, мәдәни, яшьләр һәм иҗтимагый проектларга ярдәм итү урыннары буенча тур булды. НКО җитәкчеләре һәм активистлары проектларны тормышка ашыруда ярдәм итәргә әзер булган оешмаларның эшчәнлеге белән танышты. Болар – очрашулар, лекторийлар һәм презентацияләр үткәрү, эш өчен биналар яки мәйданчыклар бирү, проектларның партнерлары булып чыгыш ясау, финанслар җәлеп итүдә яки хакимият органнары белән хезмәттәшлектә ярдәм күрсәтү, проектларны мәгълүмат белән тәэмин итүдә булышу, тар махсус мәсьәләләр буенча консультация бирү һәм башкалар. Проектта шулай ук «Рәхмәт» хәйрия фонды, Таткультресурсүзәк, «Игелекле Казан» коворкингы, Эшмәкәрләр йорты (Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды), шәһәр белем бирү үзәге катнашты.

2022 елның 8 апрелендә Бөтенроссия ачык хәйрия атналыгы кысаларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасында «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды тарафыннан әзерләнгән «Татарстан Республикасында тотрыклы үсеш факторы буларак сектора социаль партнерлык: иң яхшы практикалар һәм проектлар» җыентыгы презентациясе узды. Җыентык Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча республика советының һәм «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фондының 15 еллыгына багышланды. Чара онлайн һәм оффлайн форматта узды, үз мәйданчыгында ТР муниципаль районнарының Иҗтимагый советлары, коммерциячел булмаган 61 оешма һәм бизнес-структура вәкилләрен берләштерде. Чарада Әлмәт, Азнакай, Биектау, Түбән Кама, Чаллы һәм Казаннан социаль проектлар координаторлары катнашты. Җыентыкта соңгы биш елда республикада социаль-гуманитар хезмәттәшлекнең иң яхшы практикалары тәкъдим ителә, алар гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрүгә һәм безнең төбәкнең тотрыклы үсешенә ярдәм итә. Җыентыктагы иҗтимагый проектлар илнең тотрыклы үсешенең 17 үзара бәйле максатларына туры китереп тәкъдим ителә, алар аңлаешлы, гомумкешелек кыйммәтләрен тәшкил итә: ярлылыкны бетерү, сәламәт яшәү рәвешен тәэмин итү, сыйфатлы белем бирү, ресурсларны җаваплы куллану һәм башкалар, бу кыйммәтләр бөтен дөньяда хуплана һәм 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең милли үсеш максатларына кертелгән. Җыентыкның һәр бүлеге конкрет максатка кечкенә резюме һәм «Без ничек ярдәм итә алабыз?» рубрикасындагы җөмләләрдән тора.

Көн тәртибендә – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасында да, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасында да коммерциячел булмаган оешмалар белән очрашулар, семинарлар, зум-конференцияләр (шул исәптән Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы белән айлык киңәшмәләр, алар барлык коммерцияле булмаган оешмалар өчен дә ачык).

2022 елда Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов премиясенә гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан 115 гариза бирелгән (2021 елда чагыштыру өчен – 64).

Алар 35 муниципаль берәмлек тарафыннан тәкъдим ителгән (чагыштыру өчен: 2021 елда – 13).

Премиягә 6 дәгъвачы – башкарма хакимият органнары каршындагы Иҗтимагый советлар, 20се муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советлары, 90ы республиканың коммерциячел булмаган оешмалары тарафыннан тәкъдим ителгән. Дәгъва кылучыларның эшчәнлек юнәлешләре арасында иң күбе – 62 мөрәҗәгать – түбәндәге өлкәләрдә эшләүче гражданнарга һәм оешмаларга килде: паллиатив ярдәм, балаларга, инвалидларга социаль ярдәм; хәйрия оешмалары (36); башка социаль өлкәләрдә (22); яшьләр сәясәте (17); мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә һәм башка өлкәләрдә (15); өлкән буын гражданнарының тормыш сыйфатын күтәрү һәм өлкәннәргә социаль ярдәм күрсәтү (13); гражданлык җәмгыяте, мәгариф һәм фән институтларын үстерү, коррупциягә каршы көрәш (8); сәламәтлек саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау (4); кеше хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә (1).

Традиция буенча лауреатларны бүләкләү тантанасы Халыклар бердәмлеге көне һәм Татарстан Республикасы Конституциясе көне алдыннан узды. 5 ноябрьдә премияне Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

2022 елда гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен премия лауреатлары:

1. Туманов Дмитрий Александрович – «Созвездие-Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасының генераль директоры.

2. Шекуров Руслан Петрович, коммерциячел булмаган донорлыкны үстерү партнерлыгы Донор-Серч берлеге директоры.

3. Тимирясова Асия Витальевна – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты» шәхси югары белем бирү учреждениесе директоры.

4. «Россия Студентлар отрядлары» Бөтенроссия яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге.

5. «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы;

6. «Жемчужина Татарстана» инвалидларга булышу төбәк оешмасы.

7. АЛЬПАРИ хәйрия фонды.

8. Алексеевск муниципаль районының Әфганстанда һәм Төньяк Кавказда сугыш хәрәкәтләре ветераннарының җирле иҗтимагый оешмасы.

10 ноябрьдә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан Татарстан Республикасының коммерциячел булмаган оешмалары өчен электрон һәм цифрлы сервисларны үстерүнең юл картасын формалаштыру буенча киңәшмә уздырылды, анда Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы вәкилләре, «Татарстан Республикасы цифрлы трансформация үзәге» ДКУ белгечләре катнашты.

Киңәшмә йомгаклары буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар өчен электрон хезмәтләр форматын популярлаштыру буенча уртак чаралар үткәреләчәк (шул исәптән семинарлар форматында, инфографика урнаштыру һ.б.), шулай ук ТР Дәүләт хезмәтләре төбәк порталында коммерциячел булмаган оешмалар өчен федераль Дәүләт хезмәтләре порталында мөмкин булган хезмәтләр сервисларына сылтамалар урнаштырылган, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәсми сайтының функциональ мөмкинлекләрен үстерү өчен, Татарстан Республикасының коммерцияле булмаган оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге белән рубрикатор булдыру өчен Бәшир Рәмиев исемендәге айти-парк белән, икътисадның өченче секторын цифрлаштыру һәм гражданнар өчен коммерциячел булмаган оешмалар хезмәтләренең мөмкинлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының коммерциячел булмаган оешмалары өчен белем бирү программасы булдырылган.

Бүгенге көндә коммерциячел булмаган сектор белән эшләү өчен барлык шартлар да тудырыла, әмма бу практиканы киңәйтергә, яңа нәтиҗәле практикалар эзләргә кирәк.

#МЫВМЕСТЕ премиясе «Волонтерлар» трегы кысасында «Кешеләргә ярдәм» номинациясендә «Мин барысын да булдыра алам, мин барысын да булдырам» проекты икенче урынны алды. Аны Баулыдан Марат Ильясов төзегән. «Мин булдыра алам» СҮЗЛӘР АНО җитәкчесе Марат Ильясов авторлык тренажерлары һәм үз реабилитация методикасын уйлап таба, алар аңа аякка басарга ярдәм итә. Хәзер тренажерлар Татарстанның 6 районында һәм Башкортстанның 3 районында инвалидларны һәм физик кимчелекле кешеләрне сәламәтләндерергә ярдәм итә. Бер ел эчендә проект кысаларында 2 үзәк ачылган, 2000нән артык уку дәресе үткәрелгән, аларны 700дән артык кеше караган.

2022 елның 2 декабрендә Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин видеоконференция форматында инвалидлар һәм иҗтимагый оешма вәкилләре белән очрашу үткәрде, анда «Аякка бастыңмы – башкаларга ярдәм ит» проектын Марат Ильясов тәкъдим итте. Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин Марат Ильясовның авторлык реабилитация тренажерларын лицензияләүне озакка сузмауларын күзәтү астына алачагын белдерде һәм хөкүмәт рәисе урынбасары Татьяна Голиковадан бу мәсьәләгә игътибар итүен сорады.

Гомумән алганда, Татарстан Республикасы #МЫВМЕСТЕ-2022 премиясе финалистлары саны буенча топ-5кә керде.

«Безнең киләчәк» төбәк социаль программалары фонды оештырган «Мин дөньяны үзгәртәм» Бөтенроссия акциясе йомгаклары буенча Татарстан вәкиле – «Татарстан Республикасының шикәр диабеты белән авыручы кешеләр берләшмәсе» АКБО директоры Тимур Николаев җиңүчеләрнең берсе булды.

2015 елдан Россия Икътисадый үсеш министрлыгы ярдәме белән үткәрелә торган социаль эшкуарлык өлкәсендәге «Елның иң яхшы социаль проекты» Бөтенроссия социаль эшкуарлык проектлары бәйгесендә өлкән яшьтәге кешеләрне карау өлкәсендәге проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән коммерциячел булмаган оешманың иң яхшы социаль проекты – Полина Петрова проекты («Социаль ярдәм үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешмасы, Чаллы) булды.

Татарстаннан өч проект мәдәният учреждениеләре һәм иҗат берләшмәләре партнерлыкларын үстерүгә юнәлдерелгән Владимир Потанинның хәйрия фондыннан «Креатив музей» бәйгесендә җиңде, алар арасында «Яңа музей» коммерцияле булмаган партнерлык Казанны танып белү туризмын үстерү үзәге дә бар.

2022 елда Президент грантлары фонды 2021 елда гамәлгә ашырылган проектларның нәтиҗәләрен бәяләде. 6318 проектның нәтиҗәләре бәяләнде. Алар арасында 2019–2021 еллардагы бәйгеләрдә һәм 2018 елдагы бәйге нәтиҗәләре буенча старт алган 18 озак сроклы проектта җиңүчеләр бар.

Татарстаннан топ-100 исемлегенә 4 проект керде: Болар – Анжела Вавилова исемендәге Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү төбәк иҗтимагый хәйрия фонды – «Ярдәм чикләрен киңәйтеп – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә күчмә хезмәт белән ике паллиатив медицина ярдәме кабинетын ачу» проекты;

– мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә ярдәм итүнең автоном коммерцияле булмаган оешмасы «Мин булдыра алам» – «Аякка бастыңмы – башкаларга ярдәм ит» проекты;

– «Ак Барс Созидание» хәйрия фонды – «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны социаль адаптацияләүгә һәм һөнәри юнәлеш бирүгә ярдәм итү» проекты;

– «Ачык коммуникацияләр академиясе коммерциячел булмаган оешмасы» – «Борылыш артында диңгез» башлаучы сәнгать эшлеклеләре өчен гамәли проект» проекты.

Шулай итеп, республиканың коммерциячел булмаган оешмалары һәм хакимият органнары үзара хезмәттәшлекнең югары ноктасында дип әйтергә була, аның төп инструментлары – диалог һәм ярдәм, ә бу диалогның төп мәйданчыгы – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы.

Йомгак

2022 ел нәтиҗәләре күрсәткәнчә, коммерциячел булмаган сектор, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, республиканың гражданлык җәмгыяте традицион кыйммәтләр нигезендә иҗтимагый бердәмлекне ныгытуга ярдәм итә. Гражданлык җәмгыятенең бу практикасы РФ Президентының ноябрьдә дөнья күргән «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту турында»гы Указының нигезе булып тора.

Әлеге Указны гамәлгә ашыру, республиканы алга таба үстерү, кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрү, шулай ук икътисадның өченче секторы үсешенә ярдәм итү максатларында гражданлык берләшмәсе институтлары белән хезмәттәшлек итү эшнең төп векторлары булачак.

Узган ел иҗтимагый дипломатиягә ихтыяҗны формалаштырды, көнчыгыш партнерлар һәм тугандаш халыклар белән халыкара хезмәттәшлекне киңәйтү, мәдәни, мәгариф алмашу мөнәсәбәтләрен ныгыту кысаларында, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы бу өлкәдә иҗтимагый оешмаларның һәм коммерциячел булмаган оешмаларның иң яхшы практикаларын гомумиләштерүне дәвам итәчәк.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2022 елга ТР Дәүләт Советына Юлламасында куелган бурычларны («Иҗтимагый үсешнең иң мөһим ресурсы – гражданнарның ышанычы, аларның республика үсеше программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыруга катнашы») хәл итү максатларында, дәүләт һәм гражданлык җәмгыятенең үзара хезмәттәшлегенең яңа практикаларын алга таба үстерү зарур. Министрлыкларның, ведомстволарның һәм муниципаль берәмлекләрнең Иҗтимагый советларының иң яхшы практикаларын, аларның уңышлы тәҗрибәсен өйрәнү дәвам итәчәк.

2023 елда «Муниципалитет НКО» беренче рейтингы үткәреләчәк.

БЕР КУЛДА – КИТМӘН, ИКЕНЧЕСЕНДӘ – КАЛӘМ...

Мәгариф

...булмасын иде! Казанның күп телдә белем бирүче «Адымнар» мәктәбендә тәүге тапкыр узган республикакүләм авыл укытучылары форумында яңгыраган фикерләрнең берсе бу. Чарада районнардан килгән 500ләп кеше катнашты. Укытучылар гына түгел, җирле үзидарә башлыклары да бар иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чара «Авыл укытучылары белән данлыклы» атамасы астында узды. Исемен җисеменә туры китереп, республиканың рәсми затлары укытучылар һәм аларның дәрәҗәсе турындагы фикерләре белән уртаклашты. Әйтик, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов фикеренчә, укытучының дәрәҗәсен күтәрү – ике яклы һәм бик әһәмиятле эш.

– Укытучыларга артык күпне йөклибез инде без. Соңгы елларда бала тәртибе, белемне үзләштерү мәсьәләсендәге җаваплылыкны тулаем балалар бакчасына һәм мәктәпкә йөкләделәр. Алар гаепле булып калды. Укытучылар үзләре бер сүз әйтә алмый: баланы эшкә җәлеп итәргә, аңа кисәтү ясарга ярамый. Бу – дәүләт кенә хәл итә торган нәрсә түгел, бу очракта кешегә, җәмгыятькә фикерләү рәвешен үзгәртергә кирәк. Ә укытучы, үз чиратында, шәхес буларак үзен һәрьяклап үрнәк итеп куя белергә тиеш, – диде ул.

Инде форумда яңгыраган һәм авыл укытучыларын борчыган кайбер мәсьәләләргә күчик.

Хикмәт акчадамы? Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин фикеренчә, белем бирү өлкәсендәге барлык проблемаларны да хезмәт хакына бәйләп карау дөрес түгел. Форум вакытында катнашучылар арасында уздырган сораштыруда да (диаграмманы карагыз. – **Авт**.) бу мәсьәлә беренче урында тормый. Бу җәһәттән министр авылда эшләүче укытучыларга каралган өстәмә ярдәм чараларын санап китте. Әйтик, бу елның гыйнварыннан яшь белгечләргә 2510 сум өстәмә акча түләнә башлаган. «Аңлашыла инде, әллә ни зур сумма түгел...» – диде министр. Аның сүзләренчә, проблемалар берничә өлештән тора: белем бирү сыйфаты, яшь белгечләр, аларга теләктәшлек белдерү...

Ә яшьләрнең авылда калмавы – үзе бер зур проблема. Шуңа бәйле рәвештә авыл мәктәпләрендә яшь укытучылар бик аз. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин фикеренчә, яшьләрнең генә түгел, авыл кешеләренең шәһәргә күченүен туктата алмасак, авылда укытучыга, гомумән, эш булмаячак.

Татарстанда:

- **848** авыл мәктәбе бар (барлык мәктәпләрнең 60 проценты);
- **85908** бала авыл мәктәпләрендә белем ала;
- **12295** укытучы авыл мәктәпләрендә эшли;
- укытучыларның уртача хезмәт хакы – **44** мең сум.

АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫН НӘРСӘ БОРЧЫЙ?

33% >> мәгариф оешмаларында матди-техник шартлар
15% >> кадрлар
11% >> финанс
9% >> мәктәпләрне саклау һәм аз комплектлылык
6% >> укытучы статусы
4% >> инклюзия
3% >> интернет
19% >> башка мәсьәләләр

** форум барышында уздырылган сораштыру нәтиҗәләре*

– Күп кенә төбәкләрдә авыллар саны кими. Бөтен шартлар булуга карамастан, бездә дә шул ук хәл күзәтелә. Укытучылар җитмәү турында сүз алып барганда, авылларны саклап калу мәсьәләсенә игътибар итәргә кирәк. Моның өчен авылда эш булдырырга кирәк, – диде ул.

Иң мөһиме – бәхетле булсыннар! Россия Мәгариф академиясенең Мәгариф үсеше стратегиясе институты идарәсе башлыгы Ирина Логвинова барча укытучыларга да әнә шул теләген җиткерде. Ул да, укытучыга карата ихтирам хезмәт хакы күләме белән үлчәнми, дигән фикердә. «Сыйныф бүлмәсенә чын мәгънәсендә бәхетле кеше килеп керсә, балалар математиканы да, географияне дә бик җиңел үзләштерер иде. Укытучыларның рухи көчләре генә җитсен!» – диде ул.

Асылда авыл укытучысын нәрсә борчый соң? Билгеле, форумның пленар өлешендә генә катнашкач, чара кысасында телгә алынган барлык проблемаларны да белеп бетерә алмадык. Шуңа да кайбер укытучылар белән аерым сөйләштек. Яшерен-батырын түгел, алар ачылып сөйләшергә бик яратмый. Ниндидер эчке тыюлары бар. Шулай да бер мөгаллимә эчендәгесен сөйләде, әмма исемен язмавыбызны үтенде.

– Укытучының эше күп инде аның. Авыл җирендә кәгазь эшенә өстәп, бакчасы да бар. Бер кулда – китмән, икенчесендә – каләм, дигәндәй... Моны укытучының дәрәҗәсенә шулкадәр йогынты ясый, дип әйтә алмыйм, әмма төп эшкә комачаулый, билгеле. Аңа бит өстәп акча түләмиләр, – диде ул.

Чүгендер дә утап, балага тәрбия дә биреп, үз фәнеңә карата кызыксыну да уяту – ай-һай катлаулы нәрсә. Моны Илсур Һадиуллин да аңлый булса кирәк. «Авыл җирендә эшләүче укытучыларны башка төр вазыйфалардан азат итү мәсьәләсе мөһимнәрдән санала. Аларның төп эше – укыту һәм тәрбияләү. Бу җәһәттән җирле җитәкчелекнең мөнәсәбәте мөһим», – диде ул.

Мамадыш районының Урта Кирмән авылында тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Ринат Хәйруллин фикеренчә, мондый чара Укытучы һәм остаз елы кысасында гына узмасын иде.

– Форум ошады, дәвамлы, традицион чара булсын иде ул. Укытучылар, аларның дәрәҗәсе турында саллы фикерләр әйтелде, шактый гына борчыган мәсьәләләр күтәрелде, әмма телгә алынмаган берничәсенә игътибар итсәләр иде. Әйтик, мәктәпләрдә психологик ярдәм. Авыл мәктәпләрендә психолог өчен аерым штат юк, ул, гомумән, районга да бер-ике генә. Минемчә, ул һәр мәктәпкә кирәк. Аннан соң, террорчылыктан саклану юллары шәһәр мәктәпләрендә камилләштерелсә дә, авыл мәктәбендә үзгәреш булмады. Балаларның тыныч кына укыйсы, безнең тыныч укытасы килә бит... – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бәйге

Финалга чыктылар

Татарстан журналистика һәм массмедиа өлкәсендә «Бәллүр каләм» бәйгесенең финалына чыгучылар мәгълүм булды.

«Журналистикага тугрылык» номинациясе

1. **Нуриев** Вакыйф Вәкил улы («Татмедиа» АҖ филиалы – «Казан утлары» журналы редакциясе» җитәкчесе-баш мөхәррире урынбасары)
2. **Хәсәнова** Рузилә Рифкат кызы («Татмедиа» АҖ филиалы – «Актаныш-информ» хәбәрчесе)
3. **Әсхәдуллина** Алсу Фәһим кызы («Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖнең Иртәнге тапшырулар һәм «Пирамида» студиясе дирекциясе мөхәррире)
4. **Толмачева** Людмила Ивановна («Казанские ведомости» газетасы редакциясе)

«Мультимедияле редакция» номинациясе

1. **«Татарстан 24»** ҖЧҖ
2. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Челнинские известия»** газетасы редакциясе
3. **«Ватаным Татарстан»** газетасы редакциясе» дәүләт бюджет учреждениесе
4. **«Яңа Гасыр»** телерадиокомпаниясе» АҖ

«Нәтиҗәле матбугат хезмәте» номинациясе

1. **Түбән Кама** муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге
2. **Мөхәммәтҗанова** Римма Равил кызы (Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр идарәсе җитәкчесе)

«Туган тел» номинациясе

1. **Мусин** Фәнил Зөлкафир улы («Якташлар» газетасы мөхәррире)
2. **«Яңа Гасыр»** телерадиокомпаниясе АҖнең Магнитогорск шәһәрендәге хәбәрчеләр пункты

«Ел телеоператоры» номинациясе

1. **Вильданов** Сергей Таһир улы («Татмедиа» АҖ филиалы – «Челны ТВ» телерадиокомпаниясе телеоператоры
2. **Ключников** Андрей Валентинович («Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖнең «Семь дней» телевизион берләшмәсе телеоператоры-куючысы)

«Ел фоторепортеры» номинациясе

1. **Катушенок** Евгения Викторовна («Татмедиа» АҖ филиалы – «Челнинские известия» газетасы редакциясе фотохәбәрчесе)
2. **Захаров** Михаил Юрьевич («Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы фотографы)

«Популяр блогер» номинациясе

1. **Идрисов** Илнар Илдус улы
2. **Габидуллин** Илназ Ихсан улы
3. **Мәһдиева** Алия Рөстәм кызы
4. **Әхтәмов** Булат Марат улы
5. **Семененко** Русина Юрсановна

«Иң яхшы район (шәһәр) редакциясе» номинациясе

1. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Хезмәт даны»** газетасы редакциясе
2. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Шәһри Казан-Язмыш»** газетасы редакциясе
3. «Татмедиа» АҖ филиалы – «Сармановские ИРЦ» **«Сарман»** газетасы редакциясе
4. «Казан» журналы редакциясе
5. «Татмедиа» АҖ филиалы – «Апастово-информ **«Йолдыз»** газетасы редакциясе
6. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Әлмәт таңнары»** газетасы редакциясе

«Һөнәрендә иң яхшысы» номинациясе

1. **Мозаффарова** Эльвира Фирдүс кызы («Ирек мәйданы» газетасы хәбәрчесе)
2. **Иванычева** Ольга Викторовна («Казанские ведомости» газетасы мөхәррире)
3. **Дәүләтшин** Зөфәр Вахит улы («Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе АҖнең «Семь дней» телевизион берләшмәсе махсус хәбәрчесе)
4. **Шәрәфиева** Гөлнур Малик кызы («Татмедиа» АҖ филиалы – «Шәһри Казан» газетасы редакциясе» мөхәррире)
5. **Степанова** Ольга Михайловна («Татмедиа» АҖ филиалы – «Челнинские известия» газетасы редакциясе» хәбәрчесе
6. **Галиәхмәтова** Чулпан Наил кызы («Сөембикә» журналы мөхәррире)
7. **Трифонова** Ирина Федоровна («Татмедиа» АҖ филиалы – «Сувар» газетасы редакциясе)
8. **Мөбарәкшина** Зилә Нияз кызы («Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы, «Интертат» сайты, «Атна вакыйгалары» газетасы хәбәрчесе)
9. **Сафиуллина** Людмила Николаевна («Чаян» журналы)

«Татарстан Республикасында илкүләм проектларны яктырту буенча иң яхшы массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе» номинациясе

1. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Нурлат-информ»**
2. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Авангард»** газетасы редакциясе
3. **«Республика Татарстан»** иҗтимагый-сәяси газетасы

«Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын иң яхшы яктырту» номинациясе

1. **«Центр Медиа»** ҖЧҖ (Искандиров Алексей Геннадьевич, Шакирова Инзилә Динар кызы, Хәкимуллина Рузалия Әмир кызы)
2. **«Казанские ведомости»** газетасы редакциясе
3. **«Республика Татарстан»** иҗтимагый-сәяси газетасы

«Россия халыкларының мәдәни мирасы елын иң яхшы яктырту» номинациясе

1. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Идел»** журналы редакциясе
2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе АҖнең **«Болгар радиосы»** радиостанциясе
3. **«Казанские ведомости»** газетасы редакциясе
4. «Татмедиа» АҖ филиалы – **«Лениногорск-информ»**
5. **«Ватаным Татарстан»** газетасы редакциясе дәүләт бюджет учреждениесе
6. **«Татарстан»** дәүләт телерадиокомпаниясе

БЕРЛӘШҮ СИМВОЛЫНА ӘЙЛӘНГӘН ЙОЛДЫЗ

Ярдәм

Янгыннан зыян күргән Курган өлкәсенең Йолдыз-Эчкен авылы халкына гуманитар ярдәм төялгән машинаның чираттагысы 23 майда юлга кузгалачак. Бу хакта журналистларга матбугат очрашуында хәбәр иттеләр.

– Татарлар яшәгән һәр җирдән ярдәм килде. Әлегә кадәр телефонның тынып торганы юк, – диде Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев. – Без бөтен дөньяга үзебезнең нинди миһербанлы, бөек милләт икәнлегебезне күрсәтә алдык. Һәркем кулыннан килгән кадәр булыша. Кирәк-яраклар төялгән 20 тонналы фураны 10 майда озаткан идек. Инде икенчесе тулып килә. Районнарда яшәүче милләттәшләребез, эшмәкәрләр бик зур ярдәм кулы сузды. Әйтик, Удмуртиядән бер эшмәкәр генә дә төрле ел фасылында кия торган 500 пар аяк киеме алып киләчәген әйтте. Йолдыз-Эчкенне элеккеге халәтендә күрәсе килә. Мин бу авылның торгызылуына ышанам.

Беренче чиратта кирәкле кием-салым, азык-төлек, урын-җир белән тәэмин итү белән бергә төп максат – авылны кабаттан торгызу, аның халкын саклап калу. Очрашуда моңа кат-кат басым ясалды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров та, авылны торгызу мәсьәләсен күтәрәбез, диде.

– Бу хәбәрне алу белән үк, Татар конгрессының канаты астында эшләп килүче татар оешмалары бер йодрык булып берләште. 1,5 көн эчендә 2 млн сумнан артык акча туплый алдык. Татарстан халкыннан, оешмалардан һәм күрше төбәкләрдән гуманитар ярдәм алдык. Йолдыз – кыска гына вакыт эчендә берләшүнең бер символына әйләнде. Ул авыл бетмәячәк, сүнмәячәк. Без аны бергәләп торгызачакбыз. Безгә ничек тә моңа кадәр авылда яшәгән гаиләләрне саклап калырга кирәк, – диде ул.

Данис Шакиров әйтүенчә, хәзер беренче чиратта авылны торгызыр өчен төзелеш материаллары, җиһазлар тупланыла.

Йолдыз авылындагы хәлләрне үз күзләре белән күреп кайткан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе һәм «Интертат» сайты баш мөхәррире Рәмис Латыйпов та халыкка беренче чиратта торак йортлар җиткерергә кирәклеген әйтте. Аннары гына җиһазлар һәм йорт өчен башка кирәк-яраклар турында уйларга мөмкин булыр иде, диде ул.

– Иң күзгә ташланганы – кап-кара булып калган урман һәм көл. Бу урыннар сугыш вакытындагы фильмнардагы күренешләрне хәтерләтә иде. Мин барганда янгыннан соң дүрт көн узган иде, шул вакытка кадәр пыскып ятучы урыннар бар иде. Кеше михнәт килгәч сынала, диләр. Булышу алар өчен генә түгел, мондагы татарлар өчен дә кирәк. Беренче чиратта үзебезнең кем икәнлегебезне аңлар һәм рух ныклыгын күрсәтер өчен. Хөрмәт, кардәшлек тә, бердәмлек тә шушы вакытта сынала. Авыл халкының күпчелеге аны саклап калу яклы. Тик ярдәм итмәсәк, күпмедер халык таралып бетәчәк. Без моңа юл куймаска тиеш, – диде Рәмис Латыйпов.

«Татар-информ» / Рәмис Латыйпов

Очрашуга онлайн режимда кушылган Йолдыз авылы имамы, фермер Әхмәдулла Хәбибуллин авыр вакытларда ярдәм кулы сузган һәр кешегә елый-елый рәхмәтен әйтте.

– Бу – Аллаһның зур сынавы һәм без аны лаеклы узып чыгарга тиеш, – диде ул. – Эчкен татарларының ватаны – Йолдызны, барлык өйләрне кабаттан торгызачакбыз Иншаллаһ.

Ул коточкыч төнне фермерның чәчүгә дип әзерләгән игеннәре дә янып көлгә әйләнгән. Техникалары янган кешеләр дә күп булуын әйтте ул.

– Ләкин безгә ярдәм итүчеләр бар. Орлыгын да бирәбез, диләр. Тик мин әлегә чәчүгә керешмәдем. Башка фермерлар да зыян күрде. Алга таба барыбыз да эшләргә ниятлибез. Хезмәтебез булмаса, ашыбыз да булмаячак. Хәзер безгә кешеләр башка җиргә китмәсен өчен тырышырга кирәк, – диде ул.

Кызганыч, әлеге вакытта дәүләт ярдәмен алу белән авырлыклар бар икән. Кемнеңдер йорты – балалары исемендә, кемнекедер дәүләт реестрында теркәлмәгәнлектән, компенсация ала алмаска мөмкиннәр. Менә шул четерекле мәсьәләләрне хәл итү өчен дә тырышалар.

– Бер эшмәкәр бер гаиләгә йорт төзеп бирәчәген әйтте. Авыл халкы гомер буе мәктәптә укыткан, йорты теркәлмәгән укытучыга йорт төзергә кирәк, дигән уртак карарга килде, – диде Марс Тукаев.

Ул рәхмәт сүзләрен Урал арты татарлары Курган өлкәсе төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе урынбасары Алена Гавригина да җиткерде. «Татарстан халкы беренче минутлардан ук ярдәмгә ашыкты, Конгресс иң беренчеләрдән булып кул сузды, аңа башка татарлар да кушылды. Сез әле дә булышасыз. Йолдызны бөтен Татарстан, татарлар торгыза. Бик зур рәхмәт сезгә», – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, улы
МОРАТОВ Марсель Равил улының
гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Моратов Равил Фатыйх улының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, улы
МОРАТОВ Марсель Равил улы
вакытсыз вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Моратов Равил Фатыйх улының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, әтисе
САДЫЙКОВ Рәшит Фарук улы
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисенең матбугат җитәкчесе урынбасары Садыйкова Гөлнара Рәшит кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, «Республика Татарстан» газетасының парламент хәбәрчесе
МУШКИНА Ирина Владимировнаның
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмәнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТАИФ компанияләр төркеме коллективы, хатыны, Казан шәһәре 2 нче балалар шәһәр сырхауханәсе баш табибы
ӘХМӘДИЕВА Роза Салих кызының
вафат булуы сәбәпле, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты мәгълүмати технологияләр һәм автоматлаштырылган проектлау системалары кафедрасы профессоры Әхмәдиев Фаил Габделбәр улының, шулай ук туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Фаил Габделбәрович, бу авыр көннәрдә якын кешегезнең югалту ачысын кичерергә сабырлык, түземлек бирсен. Роза Салиховнаның – изге күңелле, мәрхәмәтле, коллегалары һәм сырхаулар арасында зур абруй казанган гүзәл кешенең – якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагы чыгарылышын КУБЫЗга багышладык. Әлеге уен коралының күп кенә төрки халыклар арасында, шул исәптән татар халкы мәдәниятендә танылуы билгеле. Бүген без аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында сөйләшербез.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

КУБЫЗ ЯСАУ ОСТАСЫ ИЛДАР ГЫЙМАДИЕВ:
«КУБЫЗНЫҢ ЯҢГЫРАШЫ ДӘВАГА ТИҢ»

Кубыз – серле инструмент. Бер мәртәбә булса да аның тавышын ишеткән кешеләр килешер моның белән. Кубыз ясау остасы Илдар ГЫЙМАДИЕВ әйтүенчә, әлеге инструмент кешенең милли узаңына да тәэсир итәргә сәләтле. Онытыла язган бу уен коралын халыкка ничек кайтарырга? Кубызда джаз һәм оркестр көйләрен дә уйнап буламы? Аның язмышы кем кулында? Без әнә шул хакта сөйләштек.

:: Илдар әфәнде, кубыз ясауга кайчан алындыгыз?
– 2010 елда кубызда уйнарга өйрәндем, 2017 елдан бирле әлеге инструментны үзем ясыйм.

:: Нәрсәсе белән җәлеп итте ул?
– Иң беренче чиратта, яңгырашы белән. Тавыш белән дәвалау дигән төшенчә (звукотерапия, яки Sound Healing. – **Авт.**) бар. Кубызга да хас ул. Моннан тыш, аның яңгырашы халкыңның тарихын өйрәнергә, рухи яктан үсәргә дә этәрә. Миндә бу уен коралын ясап кына калмыйча, бөтен дөньяга тарату теләге уянды. Кубызның тагын бер үзенчәлеге бар: музыка белеме булмаган кеше дә анда уйнарга өйрәнергә, төрле мөмкинлекләрен отып алырга сәләтле. Шуңа да мин, төрле сәфәрләр кылып, дәресләр, осталык дәресләре уздырам.

:: Белүемчә, һөнәрегез буенча сез – финансист. Ә музыка – бөтенләй башка дөнья. Бу ике дөньяны ничек бер-берсенә бәйләдегез?
– Кешегә тумыштан бик күп сәләтләр бирелә. Хыялларына тугры булып, үзен илһамландыра торган эшләр белән мавыкса, ул бу сәләтләрен тормышында файдалана ала. Кубыз ясарга өйрәнү теләгем бик көчле иде. Билгеле, мондый эшне үзлектән башкарып чыгу шактый авыр булыр иде. Шуңа да мин металл эшкәртү белән яхшы таныш булган дусларымнан, танышларымнан киңәшләр сорадым, шуларга нигезләнеп, экспериментлар аша өйрәндем. Снежинск шәһәреннән Дмитрий Глазырин (аның киңәшләре дә бик ярдәм итте), Якутиядән Иннокентий Готовцевның эшләнмәләре дә бик илһамландырды.

:: Хәзер инде үз ширкәтегез бар. Сезнең белән бергә ничә кеше эшли?
– Өч дус бергә башлаган идек, хәзер инде 20ләп кеше белән эшлибез.

Илдар Гыймадиевның шәхси архивыннан

:: Татарстанда сездән башка кубыз ясаучы осталар бармы?
– Белүемчә, тагын 2–3 остаханә бар.

:: Бер әңгәмәдә сез: «Бәхеткә, авыз кубызы ясый торган заводлар юк», – дигән булгансыз. Ә башка осталар башкача уйлый. Ягъни уен коралларын җитештерү масштабын киңәйтсәң, бәясе төшәр иде, шул рәвешле, популярлыгы да артыр иде, диләр. Бу хакта ни уйлыйсыз?
– Дөресен әйткәндә, кайчан әйткәнемне хәтерләмим дә инде. Ничек кенә булса да, хәзер мин башкача уйлыйм һәм сез әйткән фикер белән килешәм. Кубызны Татарстанда гына түгел, башка төбәкләрдә, башка илләрдә дә күпләп җитештерергә кирәк. Әйткәнемчә, әлеге инструмент кешеләрне рухи яктан үсешкә этәрү сәләтенә ия. Ә бүген адәм баласына нәкъ менә рухын кайгыртырга кирәк тә инде.

Ничә сум тора?

Илдар Гыймадиевның остаханәсендә җитештерелгән кайбер кубызларның бәяләре (рәсми сайтларындагы актуаль каталогтан алынды):
- *корычтан ясалган кубызлар – **3790** сумнан башлап **7190** сумга кадәр;*
- *титаннан ясалган кубызлар – **11290** сумнан башлап **16990** сумга кадәр;*
- *балкый торган кубызлар – **6490** сумнан башлап **8690** сумга кадәр.*

:: Кубыз – борынгы уен коралларының берсе. Әмма, кызганыч, бүген аның тавышы бик сирәк ишетелә. Сезнеңчә, бу проблеманы ничек хәл итәргә мөмкин?
– Әйткәнемчә, әлеге инструментның мөмкинлекләре бихисап. Кубызда этно, фолк, джаз юнәлешендәге, хәтта оркестр өчен атап язылган көйләрне дә башкарып була. Кубыз ярдәмендә заманча электрон музыка һәм җырлар язарга була. Мин менә шуның белән шөгыльләнәм дә инде. Төрле стильдәге көйләр, җырлар яздырып, төрле урыннарда чыгыш ясыйм.

Проблеманы хәл итү өчен, беренчедән, менә шундый заманча, яшьләргә ошый торган көйләрне күбрәк иҗат итәргә кирәк. Икенчедән, уйный белгәннәр кубызда уйнау серләрен башкаларга да өйрәтсен иде. Гомумән, музыка мәктәпләрендә дә булсын иде ул. Әйтик, Башкортстанда ул яктан мөмкинлекләр күбрәк. Якутияне дә мисал итеп китерергә була. Анда кубызда уйнарга мәктәптә үк өйрәтәләр. Һәм ул үз нәтиҗәсен дә бирә: балаларда кечкенә яшьтән үк үз мәдәниятләренә, туган телләренә кызыксыну, игътибар һәм ихтирам тәрбияләнә.

:: Илдар әфәнде, кубыз язмышы кем кулында?
– Кубызның язмышы турыдан-туры республиканың рухи халәтенә бәйле. Кубыз гына түгел, гомумән, милли инструментларның язмышы турында уйларга иде. Аларның язмышы – республика җитәкчелегенең кулында. Әйткәнемчә, мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында кубызда да уйнарга өйрәтергә кирәк. Этно инструментлар яшьләр сәясәтенең дә бер юнәлеше булырга тиеш. Шул очракта аларның киләчәге дә булачак.

Бу – кызык!

- Кубыз дуга сыман бөгелгән тимер чыбыкка юка гына тел беркетеп ясала. Кубызны авызга куеп чиртеп уйныйлар.
- Кубызның иң борынгы төрләре безнең эрага кадәр үк төркиләрнең бабаларына мәгълүм булган. Аеруча кубыз татар, башкорт, кыргыз, алтай, тыва һәм якутларның мәдәниятендә зур урын алган.
- Кубыз – тышкы кыяфәтен үзгәртмәгән борынгы халык уен коралы.
- Октябрь инкыйлабына кадәр кубыз татарларда яшертен, тавышсыз уен коралы булып йөргән һәм күпчелек утырмаларда, аулак өйләрдә генә уйналган.
- Габдулла Тукайның да кубыз тартып йөрүе мәгълүм.
- Кубыз – медитациядә киң кулланыла торган уен коралы.
- Габдерәхим Утыз Имәни XVIII гасыр азакларында Чирмешән буена утырган татар авылларында яшәүчеләрне, аларның тормыш-көнкүрешен, күңел ачуларын менә ничек тасвирлый:
  Кубыз, танбур вә най,
  Гайре уенлар.
  Килерләр уртага кыз вә җәванлар...
- Кубызда уйнаганда теш һәм казналар вибрациядән массаж алып тора, шуңа күрә кубызчының тешләре сау була.

ГАДИ БУЛЫП ТОЕЛСА ДА...

Музыкант, төрки халык уен коралларында уйнаучы оста, халыкара этнофестивальләр лауреаты Фәнил ВИЛДАНОВ та кубыз һәм аны халыкка кайтару турындагы фикерләре белән уртаклашты.

КУБЫЗНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ шунда ки, ул – беренче карашка бик гади, ә асылда бик күп мөмкинлекләргә ия булган уен коралы. Аны үзең белән теләсә кая алып барып була, чөнки кубыз кесәгә дә сыя. Тагын бер үзенчәлеге: ул һәр халыкта диярлек бар, атамасы гына төрле.

ӨСТЕНЛЕКЛЕ ЯКЛАРЫна килгәндә, кубыз үз-үзеңне ишетергә, ритмны яхшырак тоемларга өйрәтә. Физик терминнар белән әйтсәк, кубыз микротирбәнешләр ярдәмендә организмга йогынты ясый. Билгеле бер ритмда һәм сулышка игътибар итеп уйнасаң, бронхларны да чистарта, кан йөреше системасына да уңай йогынты ясый ул. Шулай ук психологик тәэсире дә бар.

Башка инструментлар белән чагыштырганда, **КУБЫЗНЫҢ ТӨЗЕЛЕШЕ** бик гади. Бу җәһәттән, әйтик, баян, гармун уйнаучыларга татар халык көйләренең кабатланмас мелизматикасын җиткерү җиңелрәк. Шуңа да алар халык күңелен яулап ала алды. Әмма, кабатлап әйтәм: кубыз гади булып тоела гына ул.

КУБЫЗНЫ ХАЛЫККА КАЙТАРЫРГА КИРӘК. Бу безнең дә борынгы төрки телле мәдәниятнең бер өлеше булуыбызны күрсәтәчәк. Кубыз ярдәмендә гаҗәеп көйләребезнең матурлыгын да ишеттерергә була бит.

НИЧЕК КАЙТАРЫРГА? Кубызның тавышы ешрак ишетелергә тиеш. Аны күбрәк күрсәтергә, коллективларга берләшергә кирәк. Әйтик, Башкортстанда шундый 260лап коллектив бар. Ә Татарстанда берәү дә юк. Билгеле, без дә бу юнәлештә эшләргә тырышабыз. Яшьләр өчен кызыклы

Фәнил Вилдановның шәхси архивыннан

булган заманча жанрлардагы көйләргә кубыз тавышын кушабыз. Төрле бәйрәм һәм фестивальләрдә осталык дәресләре уздырабыз. Әмма бу гына җитми. Кубызда шәп уйнаучы музыкантларыбыз бар. Без әлеге белемнәребез белән уртаклашырга әзер.

КУБЫЗДА ТЕЛӘСӘ КЕМ УЙНЫЙ АЛА. Дөрес тавыш чыгарганчы тырышсагыз, кубызчы исемен йөртү хокукына ия булырсыз.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ,
сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Кубыз – борынгы заманнардан бирле кулланыла торган популяр музыка коралы. Кубыз дөньяның барлык халыклары сәнгатендә дә кулланылган. Бу уен коралы төрләре Татарстан территориясендә алып барылган археологик казылмаларда да еш очрый.

Кубыз, гадәттә, ат дагасы рәвешендә бөгелеп ясалган, аның уртасына корыч тел беркетелгән була. Элекке заманда татар авылларында кубызны көмешчеләр, тимерчеләр алачыкларда чүкеп эшләгән.

Мондый кулдан ясаган борынгы кубызлар хәзерге заманда күп кенә татар гаиләләрендә әби-бабалары төсе буларак саклана. Тимерчеләр ясаган мондый кубызларның тавышы да көр чыга, тембрлары да бай, матур булып яңгырый.

Соңгы чорларда таралыш тапкан кубыз – уртасында теле булган дуга формасындагы тимер уен коралы (тимер кубыз). Андый рәвештәге музыка коралы бик күптәнге заманнардан (безнең эрага кадәр берничә мең ел элек!) үк билгеле. Кубызга охшаш җиз телләр гармун эчендә дә бар. Димәк, гармун тарихы кубыз белән бәйле.

Элеккеге ярминкәләрдә кубызларны күпләп сату да оештырылган. Аны аерым сәүдәгәрләр, тимерчеләрдән күпләп ясатып, Ташаяк, Мәкәрҗә, Эрбет, Минзәлә һәм башка ярминкәләрдә сатып, табыш алганнар.


Татар кубызының гомуми күренеше.

Татар халкы мәдәниятендә бүгенгә кадәр популяр бу уен коралларының үлчәмнәре дә, бакыр яисә тимер составлары да, атамалары да төрле булган. Аларны һәр төбәктә үзенчә атаганнар.

> *Билгеле булганча, әдәби телдә күпчелек очракларда аны кубыз, тимер кубыз буларак беләләр.Әмма фольклор экспедицияләре вакытында, мәсәлән, Татарстандагы Кама елгасының сул ягындагы кайбер авылларда авыз думбрасы дигәнен дә очратырга туры килде.*

Моннан тыш, авыз кубызы дигәне дә очрады, чөнки «кубыз» дигән төшенчәне кыллы-сызгычлы уен коралы белән тәңгәлләштерү күренеше дә бар. Хәзерге көнгә кадәр керәшен авылларында кыллы-сызгычлы уен коралын, кулдан ясалган скрипканы тотрыклы рәвештә, кыпчак заманнарыннан калган мирас буларак, һаман да кубыз диләр.

Башкортстанның көнбатыш татар авылларында исә тимер кубызны кубызгы дию очраклары да күп булды. Бу атамалар – әлбәттә, борынгылыкны саклаган атама мисаллары.

> *Кубыз уйнап, такмак әйтеп җырлаганнар, биегәннәр. Ул бигрәк тә яшьләрнең аулак өйләрдә, өмәләрдә күңел ачу коралы буларак киң кулланылган. Бу уен коралын Сабан туе, җыеннарда да яңгыратканнар.*

Кубызда күпчелек хатын-кызлар уйнаган, әмма ир-егетләр өчен дә ул ят булмаган. Кубызның популярлыгы аның матур тембрлы тавышы, башкару алымнары ансат, уңай булуы һәм кесәгә сыя торган булуына бәйле.

Тимер кубыздан тыш аның җәя кубыз дигән варианты да татарлар арасында кулланылган. Бу коралны 1980 нче еллар башында «Сорнай» ансамбле җитәкчесе Ринат Гыйлаҗев, Биектау районы авылларында күреп, үз ансамблендә дә куллана башлаган иде.

Бу корал гади җәядән гыйбарәт. Бер оч башын авыз куышлыгына (ягъни резонаторга) якын китереп, җәя сеңерен тартканда, аның тавышы көчәеп чыга. Авыз куышлыгы күләмен үзгәртеп, аның төрле обертоннарын сайлап, таныш бию-такмак көйләрен уйнап була.

Кубызда башкарылган музыка обертоннар рәте үзенчәлекләренә нигезләнә. Барлыкка китерелгән тонның биеклеге шул вакытта тавыш чыгаруда катнашкан тел өлешенең зурлыгыннан торган. Беренче иң түбән обертон чыгаруда кубыз теле тулаем яңгырый, икенче обертон чыгаруда аның яртысы гына яңгырый һ.б.

Бүген кубыз сәнгате белән яшьләр кызыксына. Әмма халык музыкасын сөючеләр, халык уен кораллары белән кызыксынучылар ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, кубыз уйнарга өйрәнү әсбаплары, кубыз өчен эшкәртелгән милли көйләрнең ноталы җыентыкларын әзерләп чыгару, кубыз коралын күпләп җитештереп пропагандалау юнәлешен ныгыту сорала.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 267

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+